ЗУР СӨЙЛӘШҮ
Владимир Путинның быелгы «туры элемтә»се үзенчәлекле узачак

> 3

ТАТАРЧА ТӘРБИЯ
Түбән Каманың 2 нче гимназиясендә тәсләргә дә мәгънә салынган

> 4

МИЛЛИЛЕК САГЫНДА
«Болгар радиосы» музыкаль премиясенә быел кемнәр лаек булды?

> 6

САБЫРЛЫК УЧАГЫ
«ВТ»ның Татарстанда яшәүче милләтләр турында махсус проекты

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 182–183 (29149–29150) | Сишәмбе | 12 декабрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

БЕРЛӘШТЕРҮЧЕ КӨЧ

Сайлау – 2024

Илдә 2024 елның язында узачак Президент сайлавына әзерлек башланды. Россия тарихында тәүге тапкыр Илбашы өчен өч көн тавыш бирәчәкбез. Әлеге вазыйфага тәүге кандидат та билгеле: Владимир Путин 2024 елда узачак Президент сайлавында катнашачагын әйтте. Бу хакта ул Кремльдә узган рәсми чарадан соң, Россия Геройлары белән аралашканда хәбәр итте.

Котелгән дә, көттергән дә яңалык бу. Халык арасында Владимир Путин киләсе Президент сайлавында катнашачакмы-юкмы дигән сорау моңа кадәр дә янгырады. Тик рәсми төстә җавап юк иде. Илдә яшәүчеләр гозерен Владимир Путинга Донецк Халык Республикасы парламенты спикеры, «Спарта» батальоны командиры Артем Жога җиткерде. «Сез – безнең Президент, сез безгә кирәк», – дип мөрәҗәгать итте ул Илбашына, алда торган сайлауга ишарәләп. Владимир Путин каршы килмәде. «Яшеримим, төрле вакытта моңа бәйле төрле уйлар булды. Әммә хәзер, сез хаклы, карар кабул итә торган вакыт. Мин Россия Президенты вазыйфасына үз кандидатурамны тәкъдим итачәкмен», – диде Владимир Путин. Әлеге яңалык Кремль диварларында узган рәсми булмаган сөйләшү барышында да, ил күләмендә дә хуплау тапты.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, ил өчен тарихи борылыш чорында Владимир Путинның шундый карарга килүе Президентка үз халкының язмышы иң зур кыйммәт булып торуын тагын бер кат күрсәтә. Аның әйтүенчә, Владимир Путин һәрвакыт кешеләрнең фикеренә һәм ярдәменә таяна.

> – Бүген, ил шундый зур басым кичергән бер мәлдә, нәкъ менә ул барыбыз өчен дә берләштерүче көч булып тора. Президент ярдәме белән республика илнең әйдәп баручы төбәкләреннән берсенә әйләнде. Татарстанда федераль программалар буенча юллар, хастаханәләр, мәктәпләр төзелә. Боларның барысы да халыкның тормышын яхшырту өчен эшләнә. Бу – яңа эш урыннары, халыкның тормыш сыйфатын яхшырту дигән сүз. Дәүләт башлыгы җитәкчелегендә илебезнең алга таба да ныгыячагына ышанам, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Гамәлдәге Илбашына халык та ышана. Бөтенроссия халык фикерен өйрәнү үзәге үткәргән соңгы сораштыру мәгълүматларына караганда, илдә яшәүчеләрнең 78,5 проценты Владимир Путинны хуплый. Респондентларның 89 проценты аның тыныч холкын югары бәяләгән. Халыкка Илбашының тәвәккәллеге һәм ихтыяр көче дә ошый икән.

vk.com

Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев әйтүенчә, көчле илгә көчле җитәкче кирәк.

– Яңалыкны ишеткәч, кәефем күтәрелде, – диде ул бу уңайдан. – Чонки хәзерге шартларда уңышлы үсүче илебезнең көче тагын да арта.

Минтимер Шәймиев фикеренчә, Владимир Путин озак еллар дәвамында төрле җаваплы вазыйфаларда эшләп үз мөмкинлекләрен исбатлап күрсәтте инде. «Ул булдырачак. Бу – дөрес сайлау», – диде ул.

Билгеле булганча, Владимир Путин моңа кадәр Россия Президенты вазыйфасына дүрт тапкыр – 2000, 2004, 2012 һәм 2018 елларда сайланды. Конституциягә төзәтмәләр кертелгәннән соң, ул 2024 елда узачак сайлауда да үз кандидатурасын тәкъдим итү хокукына ия. Киләсе сайлауда җиңгән очракта, Владимир Путин 2030 елга кадәр ил белән идарә итәчәк.

– Илдә яшәүчеләрнең күпчелегенә хәбәр үк, миңа да бу – теләгән һәм көтелгән хәбәр, – диде Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин. – Мондый авыр, катлаулы вакытта Владимир Путин күпмилләтле Россияне берләштерде һәм безнең зур Ватаныбыз тормышына кагылган планнарны уңышлы рәвештә тормышка ашыра.

Аның фикеренчә, Татарстан халкының Владимир Путин кандидатурасын хуплаячагына да шик юк.

2024 елда узачак Президент сайлавы тәүге тапкыр өч көн дәвам итәчәк. Сәяси чара 15–17 мартта узачак. Моңарчы Илбашы өчен өч көн буе тавыш биргән булмаса да, әлеге тәртип ил халкына таныш инде. Пандемия чорында, халыкның куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен, Дәүләт Думасына сайлауда шундый тәҗрибә кулланылды. Соңрак илнең кайбер төбәкләрендә аны Бердәм тавыш бирү көнендә дә файдаландылар. Үзәк сайлау комиссиясе җитәкчесе Элла Памфилова сүзләренә караганда, 25 февральдән 14 мартка кадәр алдан тавыш бирү оештырылачак. Үзенә уңайлы тавыш бирү участогын сайлауда «Мобиль сайлаучы» хезмәтеннән дә файдаланырга мөмкин булачак. Тик моның өчен алдан гариза язарга кирәк. Ерак авылларга исә махсус автобуслар җибәрергә ниятлиләр. Россия Президенты вазыйфасына кандидатларны 10 февральдән дә соңга калмыйча теркәп бетерәчәкләр. Ул арада ил күләмендә, шул исәптән Татарстанда, Президент сайлавы турында искә төшерүче игълан такталары күренә башлады инде.

Ахыры 3 нче биттә >

Тимер юл булачак

Мәскәү белән Казан арасында югары тизлекле тимер юлны проектлау эше тәгәлләнгән. «Россия тимер юллары» башлыгы урынбасары Олег Тони белдергәнчә, юл Россияне территориаль планлаштыру схемасына кергән.

Башкаладан Казанга кадәр тимер юл төзү мәсьәләсенең инде 2013 елдан бирле каралып килүен искәртеп үтәргә кирәк. Ул Мәскәүдән Казанга кадәрге юлга киткән вакытны 11,5 сәгатьтән 3,5 сәгатькә кадәр киметү мөмкинлеге бирәчәк. 2019 елда Россия Президенты дәрәҗәсендә тиз йөрешле юл төзүгә рөхсәт бирелмәде. 2020 елда вице-премьер Марат Хуснуллин, финанс чыгымнын зур булуы сәбәпле, проект буенча эшнең туктатып торылуын белдерде.

Быел августта исә Владимир Путин тиз йөрешле тимер юлны Татарстан башкаласына кадәр төзү идеясен хуплады. Проекта октябрь аенда «Главгосэкспертиза» уңай бәяләмә бирде.

Теләсә кайда шартлатма!

Татарстанда 25 декабрьдән янгынга каршы махсус режим кертелә. Пиротехника әйберләрен куллануга чикләүләр киләсе елның 8 гыйнварына кадәр дәвам итәчәк. Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин тиешле карарга кул куйган.

Документ нигезендә, бу вакытта 1–3 класслы хәтәр белән янаучы пиротехника әйберләреннән (бенгаль утлары һәм «хлопушка»лардан тыш) файдалану тыела. Шул ук вакытта сәнәгать биналары, транспорт инфраструктурасы (автомобиль юлларыннан тыш), ягулык-энергетика комплексы корылмаларыннан – 500 метр, торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы объектларыннан, автомобиль юллары, шәхси һәм күпфатирлы йортлардан 30 метрдан кубрәк ераклыкка читкә китеп кенә фейерверк ясарга яки салют атарга мөмкин.

Җирле үзидарә органнары пиротехника әйберләрен 30 һәм 500 метр ераклыкта куллану тыелган өстәмә объектлар исемлеген билгеләүгә хокуклы.

Республикада яшәүчеләр, үз чиратында, Яңа ел салютларын тиешле урында куллану очраклары турында да ашыгыч хезмәтләргә (112, 01, 02) шалтыратып хәбәр итә ала.

Җылыта

Узган чәршәмбе – пәнҗешәмбе көннәрендә – 6–7 декабрьдә Татарстанда тәүлеклек температура 9–28 градуска нормадан түбәнрәк булган.

Гидрометеоүзәк хәбәренә караганда, атна ахырында һәм ялларда төнге һәм иртәнге сәгатьләрдә һава температурасы –29…–35 градус тәшкил иткән. Төньяк һәм көнчыгыш районнарда –36…–37. Көнчыгыш районнарның чиге – Мөслимдә –39 градус булган. Көндез исә –20…–25, көнчыгыш районнарда –31 градус тәшкил иткән.

Бу атнада Татарстанда беркадәр җылыта башлаячак. Шул ук вакытта җил көчәя.

Синоптиклар мәгълүматлары буенча, чәршәмбе – 13 декабрьдә көндез термометрның терекөмеш баганасы –12…–17 градус күрсәтәчәк. Төнлә –17…–22. Секундына 17 метр тизлектә көчле җил. Пәнҗешәмбе – 14 декабрьдә көндез –10…–15 градус, төнлә –15…–20 градус буран дип көтелә.

Башлангыч фаразларга караганда, җомга – 15 декабрьдә көндез һава температурасы –8…–13 градус чикләрендә тирбәләчәк. Төнлә –13…–18 градус. Шимбә – 16 декабрьдә көндез –6…–11, төнлә –11…–16 градус. Кар-буран, көчле җил. Юлларда – кар көртләре.

Кыйммәтләнә

Республикада 27 ноябрьдән 4 декабрьгә кадәрге атнада кыяр, кишер һәм йомырка бәясе арткан.

Татарстанстат мәгълүматларына караганда, кыяр бәясе 10,62 процента артып, килосы 140,67 сумга җиткән (20–28 ноябрьдә 9,71 процентка кыйммәтләнгән булган). Икенче урында – кишер. Яшелчә хакы 5,16 процентка күтәрелеп, килосы 29,45 сум булган. Йомырка исә янә 5 сумга (4,28 процентка) кыйммәтләнеп, дистәсе 104,15 сум тәшкил иткән. Шулай ук каймак, банан, башлы суган, бәрәңге, кара чәй, икмәк кебек ризыкларның бәясе 1,2% чамасы үскән.

Бәясе төшкән продуктлар арасында исә помидор – беренче урында. Ул 5,89 процента арзанаеп, килосы 175,56 сумга калган. Моннан тыш, шикәр комы, тары ярмасы, карабодай хакы кимегән.

Сак булыгыз!

Чана түгел

Махсус урында гына шуасы! Россиядә тюбинг, «ватрушка»ларда барлык таләпләргә туры килгән ял итү урыннарында гына шуарга рөхсәт итмәкчеләр. Россия Дәүләт Думасының гаиләне саклау, ата-ана, бала мәсьәләләре буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Татьяна Буцкая шундый тәкъдим белән чыккан. Дөрес, кыш җитүгә, елның-елында шундый фикер ишетергә туры килә анысы. Әммә хәзер аны закон нигезендә беркетмәкчеләр.

– «Ватрушка» белән берничек идарә итеп булмый. Өлкәннәр аны ничек тә ияртеп ала алмый. Әмма анда бала утырса, аның бик җитди җәрәхәтләр алачагы көн кебек ачык. Шуңа күрә халык телендә тюбинг, «ватрушка» дип йөртелгән җайланмалар ярдәмендә аттракцион кебек махсус ял итү урыннарында гына шуарга кирәк, – дип проект авторы.

Кыш башланырга да өлгермәде, Чувашия, Ленинград өлкәсе, Омск шәһәрендә шундый аянычлы очраклар теркәлгән инде. Зыян күрүчеләрнең барысы да диярлек балалар. Күбесенең «ватрушка»да тау шуганда баш мие селкенгән, аяк-куллары сынган, эчке органнарына зыян килгән. Бәхеткә, әлегә Татарстанда «ватрушка»да шуып имгәнүчеләр юк. Әммә узган елларда әлеге куркыныч уенчык республикага да бик күп кешегә зыян салды.

Тюбингның ни дәрәҗәдә куркыныч җиһаз икәнлеген табиблар да гел искәртә килә. Республика балалар клиник хастаханәсенең травматология бүлеге мөдире Руслан Хәсәнов сүзләренә караганда, әлеге куркыныч җайланма сәгатенә 50 чакрым тизлек белән хәрәкәт итә. Шуңа таудан «ватрушка» белән шуып төшкән кешенең, бигрәк тә баланың, берәр кая килеп бәрелгән очракта, имгәнәсе көн кебек ачык.

– Анда шуганда бала ныклап тотына алмый. Шуңа күрә «ватрушка»да шуу еш кына баланың оча, муен сөяге җәрәхәтләнү белән тәмамлана. Баш белән аяклар да аеруча зур куркыныч яный. Кызганыч, үлемгә китергән очраклар да күзәтелә. Чана белән азмы-күпме идарә итеп була әле. Аны аяк белән туктатып калырга да, кирәк икән, янга аварга да мөмкин. Шуңа күрә «ватрушка»да махсус җайлаштырылган урыннарда гына шуарга кирәк, – ди табиб.

Белгеч балалар арасындагы имгәнү очракларын катлауландырган тагын бер җитди сәбәпне атый. Ул да булса, балаларның имгәнгән очракта да кай җире авыртуын әйтмәве. Зарланмагач, ата-ана да аны-моны абайламыйча кала.

– Әгәр бала белән урамнан кергәч, ул авыртудан зарланса, хәле бер сәгатьтән соң да рәтләнмәсә, имгәнгән урында кара көйгән тап пәйда булса, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бала үзенә хас булмаганча йокымсырап йөрсә, нейрохирурга барыгыз хәерле. Сабыйның баш мие селкенгән булырга мөмкин, – ди белгеч.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз



Марат ҖӘББАРОВ, Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры:

Хәзерге көндә аграр секторда иң кирәкле һәм белемле белгечләр аена 150 мең сумга кадәр акча ала. Болар – ветеринария өлкәсе белгечләре, агрономнар, зоотехниклар. Санлы технологияләр белән дус булган эре агрохолдингларда хезмәт хакы 60 мең сумга җитә. 2023 елның тугыз ае нәтиҗәләре буенча тармакта уртача хезмәт хакы 43 мең сумны тәшкил иткәндә бу! Моннан чыгып, нәтиҗәләрне үзегез ясагыз.

(«Татарстан» журналыннан)

РОССИЯДӘ – АВТОМОБИЛЬ

ҖИҢЕЛ МАШИНАЛАР – **45,4 млн**



1/3 >> Россия маркалары

2/3 >> чит ил маркалары

1000 РОССИЯЛЕГӘ **315 машина** ТУРЫ КИЛӘ

**Автостат мәгълүматларына нигезләнеп*

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЭССЕКИБО КЕМНЕКЕ?

Дөньякүләм ызгышлы, конфликтлы вазгыять үсешен дәвам итә. Газздәге канкоеш Якын Көнчыгышка таралу ихтимал. Кызыл диңгездә хәл катлаулана. Йәмән гыйсъянчы-сектантларының Израильнең сәүдә корабларына юлны бикләүләренә җавап итеп, АКШ һәм аның иярченнәре аларга каршы сугыш хәрәкәтләре башлап җибәрү хакында уйлана. АКШ Президентының Милли куркынычсызлык буенча киңәшчесе урынбасары Джон Файнер үткән пәнҗешәмбедә Байден администрациясенең бу мөмкинлекне күз уңында тотуын әйтте. Әмма Әфганстан сабаклары американнарны һәм европалыларны әлегә кискен хәрәкәтләрдән тотып тора. Гыйсъянчылар, үзләренә һөҗүм булганда, сугышны Согуд Гарәбстаны һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләре туфрагына күчерергә вәгъдә бирә. Шунысы кызык: зур киеренкелек фонында нефтькә бәяләр төшә. Элек Якын Көнчыгыш аз гына шылт итсә, кара алтын бәясе күккә күтәрелә иде.

Киеренкелекнең төп сәбәбе кризис билгеләренең артуында. АКШның федераль резервы 125 миллиард доллардан артык зыян күргән. Илдәге банкларның да югалтулары, үсеп, 700 миллиардка җитә язган. Калифорниядә бюджет дефициты рекордлы 68 миллиард долларга җитәчәк. Европарламент, Евросоюз илләре халкының 73 проценты киләсе елда тормыш дәрәҗәсе түбәнәюен көтә, 37 проценты түләүләрдә кыенлыклар кичерә, дип белдерә. Халыклар игътибарын хәрби конфликтларга юнәлтү – мондый чакта иң еш кулланыла торган алым.

Көтмәгәндә бөтенләй башка төбәктә – Латин Америкасында сугыш килеп чыгу ихтималлыгы пәйда булды. Венесуэла күршесе Гайананың Эссекибо төбәген үзенеке дип игълан итте. Николас Мадуро инде референдум үткәреп, указга имза куеп, яңа төбәкнең губернаторын һәм башка чиновникларны билгеләп куйды. Нефтькә һәм газга бай Эссекибо кайчандыр Венесуэланыкы булган, унтугызынчы гасырда ук Көнбатыш державалары аны башка дәүләт составына кушканнар. Венесуэлалылар шул гаделсезлеккә, 150 елга якын вакыт үткәч, чик куярга уйлыйлар. Эш шунда: Гайананың Каракаска каршы торырлык армиясе юк. Гаскәрләр бөтенләй юк дип әйтерлек, әмма ике арадагы чиктән хәрби техника һәм солдатлар белән үтәрлек түгел. Табигать шартлары комачаулый. Бразилия аша гына кереп була. Әмма Каракас үз максатына тайпылмый барырга ниятли. Вазгыятькә АКШ тыкшынса гына эш сугышка барып җитәргә мөмкин. Әмма Вашингтонда – тынлык. 14 декабрьдә ике ил Президентларының очрашуы көтелә. Эссекибо, бәлки, үзара килешү нәтиҗәсендә генә бирелер.

Россиядә

УТЫЗ ПРОЦЕНТТАН АРТЫК ЯРАМЫЙ

Россиядә йомырка тарады дәвам итә. Марш шулкадәр көчле: үткән атнада Татарстанда уртача бәягә янә 3,1 процент өстәлде. Болай кибеттә уртача бәядән 30 процент тирәсе кыйммәт йөри диетик ризык. Монысы районга бәйле, билгеле. Татарстанны бик күпкә узып киткән төбәкләр дә бар. Вазгыятькә Генпрокурор катнаша башлады: Краснов тавык йомыркасына бәяләрнең нигезсез күтәрелү фактларын ачыкларга әмер бирде. Базар икътисады принциплары белән прокурор әмере кай тирәдә кисешерләр – әле тәгаен генә әйтеп булмый. Көрәш мәйданына төрек йомыркасын чакырып кертергә җыеналар. Россельхознадзор 21 төрек предприятиесенә экспортка рөхсәт бирде инде. Тагын 17 предприятие шундый рөхсәттән файдалана башлар. Ноябрь уртасында Азәрбайҗан шундый мөмкинлек алган иде, әмма азәрбайҗанлы тавыклар безнең тавыкларны җиңә алмады: бәя күтәрелү тукталмады. Төрекләрнең үзләрендә инфляция кот очарлык. Шуңа күрә, мөгаен, алар ярдәме дә уңай нәтиҗәләргә китермәс. Аннан соң андый көндәшлек бездәге тавык фабрикаларының бөлүенә һәм баш санын киметүенә китерергә мөмкин.

Көрәш мәйданында ФАС (Монополиягә каршы федераль хезмәт) та бил тотарга тырыша. Чиновниклар ашыгыч рәвештә яңа закон проекты әвәләп ташлады. Товар бәясе 60 көн эчендә 30 проценттан да артып китә алмый – канунның асылы шуннан гыйбарәт. Росстатка ышансак, йомырка бәясе әлегә ул кысадан чыкмаган: октябрьдә үткән ел октябре белән чагыштырганда 23,8 процентка гына үскән. Кош ите 23,8 процент кына өстәгән. Вице-премьер Белоусов аппаратында канун проекты әзерләнүенең хак булуын әйткәннәр. Азык-төлек бәясен тагын берничә министрлык контрольдә тота, алар барысы да яңа канунның әзерләнүеннән хәбәрдар икән. Чик бәяләр 2024 елдан кертеләчәк, әлегә, мөгаен, прокуратура бәягә йөгән кидертеп торырга тырышыр. Бәяләрне ике ай саен 30 процентка кадәр күтәрү мөмкинлеге бирү чиновникларның гиперинфляция ихтималлыгына әзерләнүен аңлата. Законга язмасаң, бәяне алай ук күтәреп була дип кем уйлар иде әле? Кызыгы шунда: бәяләр йөгәне йомырка, ит, ипи, сөт кебек продуктларга гына киертелә. Аларның исемлеген Хөкүмәт билгеләячәк. Сәнәгать товарлары тулы иркенлектән файдалана. Фатирларга, автомобильләргә, көнкүреш техникасына, хәтта авыл хуҗалыгы техникасына, кием-салымга бәяләр катлап һәм тапкырлап күтәрелгәндә, азык-төлек җитештерүчеләр нишләргә тиеш? Сорау ачык кала.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

КЫЮ ЭШКӘ ТЕЛӘК БАР

Ике бәйге – ике йөздән артык медаль. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов башкалада «Профессионаллар» һәм «Абилимпикс» һөнәри осталык буенча чемпионат хәрәкәтләре җиңүчеләре һәм призерлары белән очрашты.

Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, ил җитәкчелеге һәм шәхсән Россия Президенты Владимир Путин ярдәме белән бездә эшче һөнәрләр буенча ярышлар яхшы үсеш алган. Аларга карата кызыксыну да, катнашучылар саны да арта.

– Татарстан һөнәри осталык буенча ярышларда югары нәтиҗәләр күрсәтә. Быел да шулай. «Абилимпикс» илкүләм чемпионатында республика җыелма командасына керүче 113 катнашучының 80е медаль яулады. Шуларның 26сы – алтын медаль. Булдырасыз! Сез – чиксез сәләт, үҗәтлек һәм талант үрнәге, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ул Татарстанның инде дүртенче ел рәттән хәрәкәттә алдынгы урыннарны саклап калуын да билгеләп үтте. Татарстан Рәисе сүзләренә караганда, «Абилимпикс»ны үстерү ул – ведомствоара зур эш, анда 80нән артык партнер-предприятие һәм министрлыклар катнаша. «Бу юнәлештә уртак эшне дәвам иттерү, мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә хезмәт базарында ихтыяҗ булган профессионаллар дәрәҗәсенә үсеп җитү мөмкинлеген тәэмин итү мөһим», – диде ул.

Быел «Профессионаллар» һөнәри осталык буенча яңа Бөтенроссия чемпионаты хәрәкәте дә старт алды. Ул «WorldSkills» барышында республикада тупланган тәҗрибәне колачлый. Әлеге хәрәкәт кысасында Татарстан җыелма командасы барлыгы 148 медаль яулаган.

– Сезнең һәр медалегез – республикабыз казанышы. Әлбәттә, системалы эш, сез, сезнең тренерлар һәм экспертларның тырышлыгы, күпсанлы күнегүләр, шулай ук уку йортлары җитәкчеләренең ярдәменнән башка мондый нәтиҗәгә ирешеп булмас иде, – диде Рөстәм Миңнеханов. – «Абилимпикс» һәм «Профессионаллар» ярышларының барлык чемпионнарын һәм призерларын югары нәтиҗәгә ирешүләре белән котлыйм. Бүген сез эш бирүчене түгел, ә алар сезне эзләргә тиеш. Нәкъ менә шуңа омтылырга кирәк. Республика алга таба да чемпионат хәрәкәтләренә ярдәм итәчәк, аларның югары стандартларын белем бирү практикасына кертәчәк.

Җавап йөзеннән, чарада катнашучылар республика җитәкчелегенә хәрәкәткә ярдәм иткәннәре өчен рәхмәт белдерде һәм киләчәктә дә югары үрләр яуларга тырышуларын әйттеләр.

tatarstan.ru

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Казан (Идел буе) федераль университетының яңартылган 6 нчы тулай торагын карады. 1976 елда төзелгән һәм 600 урынга исәпләнгән бинаны капиталь төзекләндергәннәр. Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, әлеге эшләр федераль бюджет хисабына башкарылган. Татарстан Рәисенә торак бүлмәләрне һәм гомуми файдалану урыннарын күрсәттеләр. Ул мөмкинлекләре чикләнгән студентлар өчен җиһазландырылган бүлмәләрне дә карады. Биредә үк Рөстәм Миңнеханов КФУ профкомының активист студентлары белән аралашты. Вуздагы уңай үзгәрешләрне күрүен искәртеп: «Бүген студентларга яшәү һәм уку өчен уңайлы шартлар тудыру мөһим. Алга таба да шулай дәвам итегез!» – диде Татарстан Рәисе.

Актуаль тема

СӘГАТЕ СУКТЫ

ХУҖАЛЫКЛАРНЫ ЯБЫК ЭШ РЕЖИМЫНА КҮЧӘРГӘ ӨНДИЛӘР

Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров Россиядә, шул исәптән республикада да бруцеллез таралу очраклары арту сәбәпле, хуҗалыкларга ябык эш режимына күчү кирәклеге турында әйтте. Бу нәрсәне аңлата һәм хуҗалыклар моңа әзерме? Без шул хакта белештек.

Инде узган саннарыбызда язуыбызча, быел республикада бруцеллезның ике очрагы ачыкланды. Россиядә исә аның 279 очрагы теркәлгән. Бу исә уяулыкны тагын да көчәйтергә һәм билләрне кысыбрак бууны таләп итә.

Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары Габделхак Мотыйгуллин аңлатуынча, ябык эш режимы бинаны киртәләр белән әйләндереп алу, персонал һәм кунаклар өчен санпропуск, транспортны эшкәртү өчен дезинфекция киртәләре булу, территорияне периметр буенча тулысынча саклау, терлекләрне бары тик тикшереп кенә кертү, эшчеләрнең махсус киемнәрдә эшләве, аннан соң юынулары, дезинфекция үткәрүе дигәнне аңлата.

– Киңәшмәдә Марат Җәббаров яңалык әйтмәде. Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгының приказында боларның барысы да күптәннән бар. Мөгезле эре терлекләр буенча 622 нче Боерык ул. Терлекчелек белән шөгыльләнүчеләр өчен анда язылганнарны үтәү мәҗбүри булырга тиеш. Моңа кадәр аларга җиңел караш булды. Менә хәзер таләпләрне үтәү вакыты килеп җитте. Закон үтәлергә тиеш. Хуҗалыкларга тырышырга туры киләчәк. Бу эшләрне башкару кичә кирәк иде, инде соңардык, – диде ул.

Кош-корт фабрикалары, дуңгызчылык белән шөгыльләнүче хуҗалыкларда бу таләпләрне үтәп барырга тырышалар. Ә менә мөгезле эре терлек торган фермаларда вазгыять башка иде.

– Моңа кадәр бруцеллез кебек куркыныч авырулар безнең республиканы читләтеп уза килде. Корбан бәйрәме алдыннан без ел да журналистлар белән очрашып, бруцеллез, тилчә авырулары турында әйтә киләбез. Әлеге авырулар мөгезле эре терлекләрдә дә булырга мөмкин. Быел мондый авыруларның чыгу сәбәбе – таләпләрне үтәп бетермәү һәм салкын караш нәтиҗәсе, – диде Габделхак Мотыйгуллин.

Аның сүзләренчә, саклану чаралары турында комплексларны төзегән вакытта ук уйларга кирәк: бинаны барлык таләпләргә җавап бирерлек итеп төзергә, ә малларны иминиятләштерергә. Әгәр 500 баштан күбрәк мөгезле эре терлек тотылса, бина терлекчелек оешмасы дип атала. Аннан кимрәк булса – терлекчелек хуҗалыгы. Аларның һәркайсы өчен үз таләпләре бар.

Тик бу таләпләр бүген республикадагы хуҗалыкларның ничә процентында гына үтәлә икән соң? Кызганыч, әлеге сорауга төгәл җавап бирүче булмады. Хәер, якынча саннарны үзебез дә чамалыйбыз анысы.

– Юк, без моңа әзер түгел, – ди Тәтеш районының «Нур» хуҗалыгы җитәкчесе Радик Нургалиев та. – Ул режимга күчү тиз һәм җиңел генә башкарыла торган эш түгел. Бик зур чыгымнар таләп ителә. Ясаган очракта да, бүгеннән тотынып булмый, яздан башлап, җаен эшләргә кирәк. Минем күзаллавымча, ул хәрби объекттан ким булмаска тиеш. Безнең фермаларда ике бригада эшли. Цехта әзерләнгән азыкны ике бригадага да ташыйбыз. Бөтен техника бер юлдан йөри. Шуңа күрә безнең өчен бик зур эш булачак ул.

«Нур» хуҗалыгында бүген 1200 баш терлек бар. Республикада мондый куркыныч авырулар килеп чыгу аларны да сагайткан.

– Авырулар куркыта, әлбәттә. Мисаллар күз алдыбызда бит. Никадәрле кеше эшсез кала дигән сүз. Тулы бер хуҗалыкны кабаттан торгызып, эшләтеп җибәрү өчен күпме финанс мөмкинлеге кирәк. Аны бөтен кеше булдыра да алмаска мөмкин. Санитария таләпләре бик күп. Аларның барысын үтәп бетергән очракта да, маллар, азык алыр өчен зур акча кирәк.

Ә менә Саба районының «Мәртен» хуҗалыгында һәрвакытта да таләпләрне үтәп эшләргә тырышалар.

– Без моңа кадәр дә бер техниканы да дезинфекцияләмичә уздырмый идек, эшчеләребез махсус киемнәрен киеп-салып йөри. Чит кешеләрне территориягә кертмибез, чөнки саклануыбыз үзебез өчен. Баштан ук планга кертелсә, аның берние дә юк, – диде хуҗалык җитәкчесе Әскәр Фатыйхов.

Зөһрә САДЫЙКОВА

tatar-inform.ru

Ныклы нигез

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИНның Россия Федерациясе Конституциясе көне уңаеннан КОТЛАВЫ

Хөрмәтле татарстанлылар! Сезне чын күңелдән Россия Федерациясе Конституциясе көне белән котлыйм.

Моннан нәкъ утыз ел элек, 1993 елның 12 декабрендә, Россия дәүләтенең язмышын хәл иткән вакыйга булды. Аның күпгасырлык тарихында беренче мәртәбә бөтенхалык референдумында яңа Россиянең Төп Законы кабул ителде. Ул иксез-чиксез илебезнең миллионнарча гражданнары – милләте, дине һәм сәяси фикерләве төрле булган, аңлы рәвештә нык демократик һәм социаль дәүләт төзүне сайлаган кешеләрнең өметләрен һәм ышанычын гәүдәләндерә.

Гамәлдәге Конституция авыр вакытта – җитди иҗтимагый-сәяси тетрәнүләр һәм дәүләт корылышының тамырдан үзгәрү чорында эшләнде. Советлар Союзы таркалганнан соң, дәверләр борылышында нормалар чыгару буенча җентекле эш үткәрелде, граждан җәмгыяте институтлары, хакимият тармаклары һәм дәрәҗәләре арасында яңа мөнәсәбәтләрне җайга салучы нигез закон актлары кабул ителде (билгеле булганча, бу ел Федераль Собраниенең, илебезнең сайлау системасының да юбилей елы). Иң югары юридик статуска ия булган 1993 елгы Конституция Россия җәмгыятенең төп кыйммәтләрен – граждан хокуклары һәм ирекләренең үзгәрмәс хәлен, дәүләт бердәмлеген һәм территориаль бөтенлекне саклауны, идеология күптөрлелеген, ирекле сайлауларны һәм күппартиялелекне, төп социаль гарантияләрне ышанычлы беркетте.

Заман таләпләренә җавап биреп, 2020 елда Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинның башлангычы белән гамәлгә ашырылган конституция реформасы нәтиҗәсендә бөтенхалык тавыш бирү йомгаклары буенча Төп Законның яңа редакциясе кабул ителде. Халыкның күпчелеге хуплаган төзәтмәләр арасында: дәүләтнең социаль әһәмиятен арттыру, тарихи хәтерне саклау, традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне, тел һәм милләт күптөрлелеген, аналарны һәм балаларны яклау... Соңгы вакыттагы вакыйгалар бу үзгәрешләрнең дәүләт һәм икътисад суверенитетын тәэмин итү, Россия Федерациясе гражданнары хокукларын һәм ирекләрен алга таба да ныгыту өчен никадәр мөһим һәм үз вакытында булганын ачык күрсәтә.

Кадерле ватандашлар! Ышанам ки, Конституция нормалары һәм нигезләмәләренә таянып, уртак максатларга ирешүдә бөтен көчебезне берләштереп, без Ватаныбызны социаль-икътисадый яктан үстерү, яшәү сыйфатын югарырак дәрәҗәгә күтәрү бурычын хәл кылачакбыз. Шушы эшләрдә безгә бәхет һәм уңышлар юлдаш булсын. Сезгә ихлас күңелдән тынычлык, нык сәламәтлек һәм иминлек телим. Бәйрәм белән! Россия Конституциясе көне белән!

Беренчесе

Казанда Кыргызстанның тәүге Генераль консулы пәйда булды. Эрик Бейшембиев әле ноябрь аенда гына бездә дипломатик эшчәнлегенә керешә. Татарстан башкаласында Генераль консуллык ачу турында быел май аенда карар кабул ителгән иде. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин кичә Кыргызстан дипломаты белән очрашты.

Фәрит Мөхәммәтшин Эрик Бейшембиевны Дәүләт Советы депутатлары исеменнән сәламләп, Татарстандагы эшчәнлеген башлап җибәрүе уңаеннан котлады. «Казандагы Генераль консуллыкка күп еллар буе Кыргызстан Тышкы эшләр министрлыгында җаваплы вазыйфаларда хезмәт куйган кешенең җитәкчелек итүенә шатбыз», – дип басым ясап әйтте парламент башлыгы.

Дәүләт Советы Рәисе билгеләп үткәнчә, Кыргызстанның Генераль консуллыгы ачылу әлеге ил белән Татарстан арасындагы хезмәттәшлеккә яңа этәргеч бирергә тиеш.

Генераль консул, үз чиратында, барлык юнәлешләр буенча хезмәттәшлекне ныгытырга кирәклеген искәртте. «Сәүдә-икътисадый гына түгел, гуманитар бәйләнешләрне да ныгыту шарт. Генераль консуллык ачылгач, үзара элемтәләрнең үсәчәгенә ышанам», – дип билгеләп үтте ул.

Берләштерүче көч

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Фикер

**Раил ГАБДРАХМАНОВ,
Россия Герое:**
– Владимир Путинның әлеге карарны кабул итүенә, националистларга каршы хәрби көрәшебезнең барлык этаплары да аның җитәкчелегендә узуына сөенәм. Катлаулы чорда ул күпмилләтле илебезне, барлык көчләрне берләштерә һәм дөрес карар кабул итә алды. Болар барысы да фронтта сизелә һәм күренә.

**Салават ФӘТХЕТДИНОВ,
Россиянең атказанган артисты, Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты:**
– Башкача була да алмый. Владимир Владимирович башлаган эшләр байтак һәм ул аларны төгәлләргә тиеш. Ул – бик тәгаен кеше. Эш кешесе. Улыма әйткәнемчә, Владимир Путин – ил тарихында беренче аек фикер йөртүче Президент, бу туры һәм күчерелмә мәгънәсендә дә шулай. Бу яктан без оттык.

**Ринат ФАЗЫЛОВ,
Бөтенроссия халык фронтының Татарстандагы төбәк башкарма комитеты җитәкчесе:**
– Мин үземне Илбашыбыз Владимир Путин командасы әгъзасы дип саныйм. Шуңа күрә аның Россия Президенты сайлавында катнашуын тулысынча хуплыйм. Президентыбыз хәзерге кебек тарихи чорда илебез, күпмилләтле халкыбыз язмышы өчен җаваплылык алудан курыкмавын тагын бер кат раслады. Ватаныбызның киләчәге өчен борчылган һәркем Владимир Путинның Россия Президенты сайлавында катнашуы турында игълан итүен зур сабырсызлык белән көтте. Ул – дөнья күләмендә үз иле, үз халкы турында уйлаучы көчле лидерларның берсе.

**Арман КОСТАНЯН,
республика «Ел укытучысы – 2023» бәйгесе җиңүчесе:**
– Илбашының үз кандидатурасын тәкъдим итүе бик әйбәт. Ни өчен дигәндә, аңа тиңдәш булырдай башка кеше юк. Владимир Путин – җитди лидер. Мин моны аның белән булган очрашудан да чыгып әйтәм. Владимир Путин кебек җитәкче булганда, бар да яхшы булачак. Бездә бүген болай да хәлләр бик әйбәт. Сайлауда кем җиңәсен исә халык үзе сайлаячак.

**Шамил ЯКУПОВ,
Татарстанның «Студентлар лигасы» президенты:**
– Бу хәбәрне куанып кабул иттек. «Студентлар лигасы» 1996 елда – моннан 27 ел элек оешкан. Бу вакыт эчендә күп нәрсә үзгәрде. Яшьләр өчен мөмкинлекләр артты. Әйтик, махсус конкурс нигезендә фатир бирү, транспорт гранты, бик күп проектлар тормышка ашырыла. Яшьләр мөмкинлекләр мохитендә яши. Владимир Путин яшьләр тәкъдимнәрен хуплый. Әйтик, әле күптән түгел генә фән белән шөгыльләнүче аспирантларның стипендиясен арттыру турында да билгеле булды. Мин үзем дә – аспирант. 15 мең стипендия алган егеткә 75 мең сум алу күпкә яхшырак бит.

moskva-putinu.ru

МӨҺИМ СӨЙЛӘШҮ

Махсус хәрби операция, тышкы сәясәт, юл, медицина, торак. Россия халкы ил Президенты Владимир Путинга сорау бирергә әзерләнә. Җавапны озак көтәсе калмады – пәнҗешәмбе дәүләт җитәкчесе үз сүзен әйтәчәк. Шунысы да бар: быел традицион «туры элемтә» һәм журналистлар катнашындагы пресс-конференция берләштереләчәк.

Пәнҗешәмбе буласы чарага әзерлек бара инде. Колл-үзәкләрдә сораулар кабул итү, мөрәҗәгатьләр эшкәртү белән мәшгульләр. Хәзергә 600 меңнән артык мөрәҗәгать кабул ителгән. Колл-үзәккә шалтыратучылар сораулар гына юллап калмый, идея, тәкъдимнәре белән дә уртаклаша икән.

Россия Президенты Владимир Путинның матбугат сәркатибе Дмитрий Песков хәбәр иткәнчә, сорауларның күпчелеге халык теленнән төшмәгән махсус хәрби операциягә бәйле. Социаль юнәлештәге сораулар да кызыксындыра. Бигрәк тә медицинага бәйлеләре күп, дип искәртә Песков.

«Халык фронты» башкарма комитеты рәисе Михаил Кузнецов әйтүенчә, дәүләт башлыгы кайсы сорауга җавап бирәсен үзе хәл итәчәк. «Безнең төп максатыбыз – бер генә мөрәҗәгатьне дә күз уңыннан ычкындырмау, иң соңгы сорауга кадәр эшләү, килеп чыккан проблемаларны хәл итү. Әлбәттә, фейк-хәбәрләр дә булачак. Без моңа каршы торырга әзерләнәбез», – диде Михаил Кузнецов.

Әлеге вакыйгадан нәрсә көтәргә? Ни өчен аны карарга кирәк? Россия Иҗтимагый палатасында Татарстан вәкиле, Хокукый мәсьәләләр һәм иҗтимагый контроль комиссиясе җитәкчесе, Россия Юристлар ассоциациясенең Татарстан төбәк бүлеге башкарма комитеты рәисе Тимур Какохоның фикерен белештек.

– Мондый форматта бу чара беренче мәртәбә үткәрелә. Ягъни «туры элемтә» матбугат конференциясе белән берләштерелә. Халык белән дә, журналистлар белән дә бер үк вакытта әңгәмә корылачак, – диде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

НИЧЕК СОРАУ БИРЕРГӘ?

- **8-800-200-40-40** номеры буенча шалтыратырга;
- **0-40-40** номерына смс юлларга;
- **«Москва-путину.рф»** сайтындагы махсус бүлектә, социаль челтәрләрдәге чат-бот.

Шунысын да искәртик: барлык мөрәҗәгатьләргә дә (шул исәптән эфирга эләкмәгәннәренә дә!) җавап биреләчәк. Ул сорауларга җирле хакимият яисә «Халык фронты» активистлары җавап әзерләячәк.

НИЧЕК КАРАРГА?

- **Кайчан?** 14 декабрьдә.
- **Кайдан?** «Беренче канал», «Россия 1», «Россия 24», НТВ, ОТР, «Мир» каналларыннан; «Маяк», «Вести FM», «Радио России» радиоканалларыннан тыңларга.

Сан

- ✓ Владимир Путин **2001** елдан башлап халык белән шушындый форматта аралаша.
- ✓ «Туры элемтә»нең соңгысы **2021** елның июнь аенда узган иде. Ул **3** сәгать **42** минут барды. Ил башлыгы **70**ләп сорауга җавап бирде.
- ✓ **2020** елның **17** декабрендә Владимир Путин катнаш форматта (видеоконференция һәм туры эфир) журналистлар белән очрашты. Бу чара **4** сәгать 29 минут дәвам итте. Дәүләт җитәкчесе **68** сорауга җавап биреп өлгерде.
- ✓ Зур пресс-конференциянең соңгысы **2021** елның **23** декабрендә узган иде. Анда **500**ләп журналист катнашты. **2022** елда пресс-конференция дә, «туры элемтә» дә оештырылмады.

Матбугат конференциясен карарга кирәк, ди Тимур Какохо.

– Бу үзенә күрә социологик сораштыру, җәмгыятьне нәрсә борчый дигән сорауга җавап эзләү. Тәҗрибә күрсәткәнчә, чарадагы сораулар һәрвакыт төрле юнәлештә була: бик глобальдән алып аерым урам, ишегалды проблемаларына кадәр. Шул исәптән халык шәхси сорауларын да юллый, – диде ул.

Әңгәмәдәшебез фаразлавынча, махсус хәрби операция темасы иң төп темаларның берсе булачак. Беренче чиратта аның кайчан төгәлләнәчәге кызыксындырачак халыкны. «Демография, инфляция, коммуналь хезмәтләргә түләү, эчке базарда эшче куллар җитмәү кебек сораулар да актуаль булачак», – диде Тимур Какохо.

Моннан тыш Россиянең казанышларына да игътибар бирелер дип өметләнә әңгәмәдәшебез. Чит ил санкцияләренә карамастан, ил аягында нык басып тора бит. Вакыт күрсәтер, кыскасы.

БАРАСЫ ЮЛ БИЛГЕЛЕ

Халык өчен эшләргә, Президент тирәсендә берләшергә! «Бердәм Россия»нең Татарстан төбәк бүлеге конференциясендә узып баручы елга нәтиҗә ясап, киләсесенә бурычлар билгеләделәр. Рөстәм Миңнеханов, Александр Сидякин һәм Фәрит Мөхәммәтшин киләсе ел турында сөйләде, Минтимер Шәймиев исә тарихны искә төшерде.

Узган атнада республиканың төп сәяси чарасына әверелгән конференция Казанның Дәрвишләр бистәсендә – ТАССР Халык комиссарлары советының беренче рәисе Сәхипгәрәй Сәетгалиев исемен йөрткән мәдәният сараенда узды. Атнаның иң салкын көне булып истә калган 9 декабрьдә район һәм шәһәрләрдән җыелган делегатлар чара башланганчы бер-берсенең хәлен белеште, яңалыклары белән уртаклашты. Урамда салкын булса да, күңелләр күтәренке иде. «Шул юлдан барабыз», – диде аларның берсе «ВТ» хәбәрчесенә, Яңа елга нинди планнар барлыгын сорагач.

35 нче конференция Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, партиянең Генераль Советы секретаре урынбасары, Үзәк Башкарма комитеты җитәкчесе Александр Сидякин һәм Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия»нең төбәк бүлеге секретаре Фәрит Мөхәммәтшин сәхнәгә күтәрелгәч башланды. Рөстәм Миңнеханов үз чыгышында партиянең зур үсеш юлы узганын, эше белән кешеләрнең ышанычын яулаганын, Россия Президенты Владимир Путинның ышанычлы таянычына әверелгәнен, ил үсешенә зур өлеш керткәнен әйтте. Татарстан Рәисе дә, башкалар да 1 декабрьдә 22 еллыгын билгеләп үткән партияне оештыручылар арасында Минтимер Шәймиев тә булганын искә алды.

Партиянең эшчәнлеге турында сөйләгәндә Рөстәм Миңнеханов «Халык программасы»н тормышка ашыру, Лисичанск һәм Рубежное калаларына республика ярдәме, сайлаучылар белән корылган элемтәне аерым телгә алды. Ә киләсе елда безне сайлау көтә. Россия Президентын сайлау «Бердәм Россия»нең алдагы эшчәнлегендә турыдан-туры чагылыш табачак. «Республика Президент курсын һәм аның карарын тулысынча хуплый. Бүген бердәмлегебез һәм бергәлегебез аеруча мөһим. Татарстанлылар дөрес сайлар дип ышанам», – диде Рөстәм Миңнеханов. Киләсе елда Татарстан Дәүләт Советы депутатларын да сайлаячакбыз. «Партиянең нәтиҗәле эше алдагы сайлау нәтиҗәләрендә чагылыш табачак. Бездә дәүләт дәрәҗәсендәге зур бурычларны хәл итә алырлык башка сәяси көч юк. «Бердәм Россия»гә зур җаваплылык йөкләнә», – диде Татарстан Рәисе.

Чыгышын татарча сәламләүдән башлаган Александр Сидякин да партиянең төбәк бүлегенә Мәскәүдән зур өметләр белән караганнарын әйтте. «Без «Бердәм Россия»нең Татарстанда иң актив һәм күпсанлы сәяси көчләрнең берсе булуына шатбыз. Татарстандагы бердәмроссиялеләрнең дә ил җитәкчелеге тирәсендә берләшәсенә ышанабыз. Ничек эшләргә кирәклеген күрсәткәнегез өчен рәхмәт», – диде ул. Александр Сидякин кулыннан партия рәисе Дмитрий Медведев имзалаган Рәхмәт хатын алган Минтимер Шәймиев исә партиянең ничек корылуы турында бәйнә-бәйнә сөйләгәндә, аның исеменә салынган мәгънәне истән чыгармаска кушты. «Безнең көч – бердәмлектә», – диде ул.

Көч һәм бердәмлеккә ирешү өчен партиянең Татарстан бүлегениләр эшләде? Узып баручы елга нәтиҗәне Фәрит Мөхәммәтшин ясады. Татарстан Парламенты башлыгы әйтүенчә, хәзерге вакытта республикада башкарма хакимият белән берлектә 24 федераль һәм 4 төбәк партия проекты, 200дән артык җирле бүлекчә проекты гамәлгә ашырыла. «Алар барысы да халыкның сорауларын һәм җирле үзенчәлекләрне исәпкә ала, конкрет күрсәткечләргә ия», – дип сөйләде ул. Партиянең төп документы – «Бердәм Россия»нең Халык программасы да халыктан җыелган мөрәҗәгатьләр буенча барлыкка килгән. Узган сайлаулар барышында 2,5 миллионнан артык мөрәҗәгать кабул ителгән, шуларның 20 меңнән артыгы – Татарстанда яшәүчеләрдән. Бүген аларның яртысыннан артыграгы үтәлгән инде. Республикадагы бердәмроссиялеләр контролендә 6 меңгә якын тәкъдим бар. Партия рәисе Дмитрий Медведевның төбәк кабул итү бүлегенә быел 10 айда 5,4 меңнән артык мөрәҗәгать килеп ирешкән. Халыкны борчыган төп проблемалар: социаль яклау, торак-коммуналь хезмәт, хезмәт хакы мәсьәләләре. Әмма төп күрсәткеч сан түгел. «Иң мөһиме – сыйфат. Халык бездән чын ярдәм көтә», – диде Фәрит Мөхәммәтшин. Алдагы елда бигрәк тә. Төбәк бүлеге Секретаре партия эшчәнлегендә иң яхшы җирле бүлекләрне дә атады. Алдынгылар сафында Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Апас, Арча, Биектау һәм Питрәч телгә алынса, калышканнар арасында Аксубай, Кама Тамагы, Лаеш һәм Мөслим барлыгын белдек.

«Президент партиясе буларак, без ил лидеры Владимир Путин тирәсендә кабат берләшергә тиешбез», – дип кабатлады Фәрит Мөхәммәтшин, киләсе елга бурычлар турында сөйләгәндә. Аңламаслык түгел иде. Бу атнада исә республика делегациясе Мәскәүгә партия съездына бара.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

«Бердәм Россия» – Татарстанда

120060 әгъза
45 җирле бүлек
2011 беренчел бүлек
18500 тарафдар

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең машиналарны эксплуатацияләү һәм төзекләндерү кафедрасы мөдире **Әдһәмов** Наил Рашат улына, «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең таксация һәм урман хуҗалыгы тармагы икътисады кафедрасы мөдире **Глушко** Сергей Геннадьевичка, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы» муниципаль берәмлеге муниципаль казна учреждениесе аппараты җитәкчесе **Афанасьев** Алексей Павловичка, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Әшнәк авыл җирлеге башлыгы **Хөснетдинова** Резеда Әхәт кызына, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Кичүчат авыл җирлеге башлыгы **Шәйхетдинов** Равил Хаматгата улына, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Яшьлек» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тренеры-укытучысы **Бариев** Ларис Хәмбәл улына, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Олимп» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең хоккей буенча тренеры-укытучысы **Галимҗанов** Илнур Камил улына, «Татарстан Республикасының армия, авиация һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт төбәк берләшмәсенең Арча җирле оешмасы советы рәисе **Алиев** Рөстәм Ринат улына, «Татарстан Республикасының армия, авиация һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт төбәк берләшмәсе автомобиль йөртүчесе **Гусев** Андрей Александровичка, «Татарстан Республикасының армия, авиация һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт төбәк берләшмәсенең Тәтеш автомобиль мәктәбе» һөнәри белем бирү учреждениесе башлыгы **Колсанов** Александр Геннадьевичка, «Татарстан Республикасының армия, авиация һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт төбәк берләшмәсенең һөнәри белем бирү бүлеге башлыгы **Мурзин** Альберт Мәгъфурҗан улына, «Татарстан Республикасының армия, авиация һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт төбәк берләшмәсенең Сарман җирле оешмасы советы рәисе **Хаҗиев** Альберт Миңневәли улына, «Татарстан Республикасының армия, авиация һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт төбәк берләшмәсенең Лениногорск автомобиль мәктәбе» һөнәри белем бирү учреждениесе башлыгы **Чумарина** Ирина Александровнага, «Белем бирүдә мәгълүмат технологияләре үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры, «Крутушка» халыкара этник фестиваленең оештыру комитеты рәисе **Бикмуллина** Лариса Владимировнага, «Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе (академиясе)» федераль дәүләт бюджет югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесенең халык уен кораллары, җыр сәнгате һәм татар музыка сәнгате факультеты деканы, этник музыканы өйрәнү кафедрасы мөдире **Сәрвәрова** Лилия Илдус кызына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге полиция участок уполномоченныйлары һәм балигъ булмаганнар эшләре бүлеге башлыгы урынбасары, полиция подполковнигы **Мәмлиев** Рамазан Фидрәт улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны, отставкадагы милиция полковнигы **Рафиков** Наил Рәсим улына, «СтройИнжиниринг» инвестиция төзелеш корпорациясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте хезмәткәрләре: кече йөктөягеч машина йөртүчесе **Абдрашитов** Дамир Фаяз улына, ташчылар бригадасы бригадиры **Казначеев** Валерий Николаевичка, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәрләре: эшләр идарәчесе **Абзалов** Рөстәм Фәрит улына, директор урынбасары **Гревцов** Андрей Борисовичка, Социалистик Хезмәт Герое **Зантимирова** Гөлсинә Хөснулла кызына, «Казан оптика-механика заводы» акционер җәмгыяте генераль директоры **Максимов** Вадим Валерьевичка, «Вакууммаш» акционер җәмгыяте механика-җыю производствосының эретеп ябыштыру участогы диспетчеры **Фәхриева** Рәсимә Нургаян кызына, Татарстан Республикасының **«Буа дәүләт драма театры» дәүләт автоном мәдәният учреждениесе коллективына Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

* * *

Республиканың социаль-икътисадый үсешенә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасының Чехия Республикасындагы сәүдә-икътисадый вәкиле **Абдулгалиев** Зөфәр Тәлгать улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «БЕРДӘМ РОССИЯ» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлекчәсе Төбәк башкарма комитеты җитәкчесе **Сәмигуллин** Марат Тәлгать улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры **Гобәйдуллин** Эмиль Фидаил улына **«Татарстан Республикасының атказанган яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Вакыт һәм без

Ерак дәверләрдә өлкәнрәкләр яшь буынга, аларның кыланмышларына карап: «Вакытлар, тәртипләр, диген син...» – дип зарланырга яраткан, диләр. Борынгы римлылардан калган мәгълүм ул гыйбарә русча «О времена, о нравы...» рәвешендә яңгырый. Буыннарның гына түгел, һәр чорның үз гадәт, кагыйдәләре, тәртипләре, хәтта үз әхлагы булган. Үз даһие, үз изгеләре, үз залим, вәхшиләре. Залимнәр хакында сүз кузгатканда, Такташның «Һәр заманның үзенә күрә була сволочы, каһәр суккыры»сы да искә төшми калмый. Тик язма алар хакында түгел, вакыт галиҗәнапларының үзе турында иде. Чорлар, дәверләр, тәртипләр алышынганда да адәми затның холык-фигыле, зурдан алганда, элеккечә калуы турында.

Ә дөнья шулай корылган: анда бар нәрсә дә үзгәрештә. Таш кыялар җимерелә, тимер тутыга-тутыга көпшәкләнеп бетә, тигез җирләр түмгәккә әйләнә, түмгәкләр тигезләнә. Вакыт бернәрсәне дә кызганмый. Без «вакыт үтә» дияргә яратабыз. Бәлки кемнеңдер: «Вакыт ул – мәңгелек, вакыт түгел, без үтәбез», – дигәне дөресрәктер. Еллар гына түгел, тезелеп дигәндәй бер-бер артлы буыннар алышына, тыныч яисә давыллы заманнар тарихта кала, яңа чорда яңа вакыйгалар булып, искеләрен оныттыра. Буыннар гына түгел, шул буыннар булдырган, юктан бар иткәннәр дә тузанга әйләнә килә.

Термодинамика фәнендә энтропия дигән төшенчә бар. Гади тел белән әйткәндә, ул Җир йөзендә нәрсә, нинди материаль әйбер бар, барысының да тузуга, юкка чыгуга юнәлүен аңлата. Иң югары энтропия иң югары системасызлык, тәртипсезлекне билгели. Өстебездәге күлмәктән алып тимер-бетоннан торгызылган мәһабәт биналарга кадәр барысы да энтропияне арттыру юлында. Борынгы Болгарыбыз мең ел элек гөрләп торган олы шәһәр булган. Бүген ул чордан санаулы корылмалар гына калган. Тагын мең ел узуга алардан да таш өеме генә калачак. Максималь энтропия. Без яшәгән чынбарлык тәртипне, оешканлыкны, кеше кулы булдырганның озак яшәвен яратмый, ул аны туздыру, җимерү ягында. Нәкъ менә шул тузуны без вакыт дип кабул итмибез микән?!

Кеше баласы вакыт узуын кулындагы сәгатьтән дә бигрәк, таң атып, санаулы мизгелләр үтүгә кич җитүдән, бер көнне икенчесе алыштырудан чамалый. Атналар, айлар алышынудан. «Кичә генә әле февраль иде, бүген давыл кырга кар ташый, март аеның нечкә билле җиле, сузылып ятып җиргә, кар ашый...» Марттагы без февральдәге без түгел инде, тузуга, ахыр килеп югалуга таба чираттагы адымнар атланган, энтропия билгеле бер дәрәҗәдә арткан. Тик кеше, ул гына түгел, тереклек ияләре, шул ук үсемлекләр белән хайваннар энтропияне, аның белән бергә вакытны да үзләренчә алдарга өйрәнгән. Ничек итеп? Нәсел, дәвамчы калдырып. Бу хәл, әлбәттә, үзе бер могҗиза. Нәкъ шул сәбәпле кечкенә генә черки иң зур, иң көчле компьютердан да мең, миллион тапкыр катлаулырак. Ул гына да түгел, гап-гади тары бөртеге дә катлаулырак. Аны җиргә күмдеңме, ул шытып чыга, үсә, серкәләнә, бер тарыдан дистәләгән яңа бөртек ярала. Кеше, үзен әллә кемгә санап, нинди генә шаккатмалы, акыллы җиһаз ясамасын, ул барыбер примитив, ул әйбер үрчергә, нәселен дәвам итәргә сәләтсез.

Сүз вакыт хакында бит әле. Без вакытны әрәм итмәскә, дөрес файдаланырга, аның кадерен белергә тырышабыз. Ягъни кыска вакыт аралыгында булдыра алганча күбрәк эш эшләп калырга. Көн тудымы, үзебез үк уйлап тапкан мең төрле мәшәкатьтән арыну юлына басабыз. Ә икенче көнгә аларның яңалары ярала. Нидер төзибез, булмаганны булдырабыз, нәрсәнедер тәртипкә китерәбез. Кыскасы, тирә-ягыбыздагы энтропияне киметергә тырышабыз. Кешенең эшчәнлеге шуңа юнәлтелгән. Вакытны нәтиҗәлерәк файдалану өчен без эшкә автомобильдә барабыз, өске катка лифтта күтәреләбез, иртән кырынганда, тиз булсын дип, электр кырынгычыннан файдаланабыз. Тик, ни гаҗәп, вакытны җиткерә алмыйбыз – һәрдаим цейтнотта калабыз. Шәһәрләр, олы мегаполисларда бу хәл бигрәк тә нык сизелә. Шуңа җиттек: китап укырга, кунакка барырга, кичке шәфәкъ белән хозурланырга да вакытыбыз юк безнең. Ник шулай соң?

Кеше бер кыбырсык зат булганга. Цивилизациялелек дип аталган халәт бездән идән астында чинашып чапкан тычканнар ясады. Гомер кирәкмәгән кыйммәтләр артыннан чабып, узышып уза. Без үзебез үк тудырган кыбырсык, меркантиль дөнья кармагында. Үлгән сыер әллә чыннан да сөтлерәк микән? Әле кайчан гына бер-беребезгә озын, эчтәлекле, җылы хатлар яза, язышa идек. Бүген хатны «Ватсап»тагы ике коры җөмлә алыштыра. Сүз озынайтып торырга безнең вакытыбыз юк.

Эшем иясенә, биологик роботка әверелдеңме, вакыт катастрофик төстә җитми. Ә бит вакыт чынлыкта бар, ул беркая да китмәде, ул җитәрлек. Без аны кирәгенчә файдалана белмибез, чөнки, әйткәнемчә, кирәкмәгән кыйммәтләр артыннан чабабыз. Уңайлыклар күпме булса да, аз, җиһазлар шулай ук. Мин-минлегебезне, статусыбызны даими арттырырга, карьера ясарга атлыгабыз. Җиһандагы төп билгеләнешебез генә читтә кала. Кеше кеше булып яшәргә өлгерә алмый кала. Кыбырсыклык, өзлексез дөнья куу аркасында ул үз асылын ача алмыйча картая. Яшәүнең тәмен тоймыйча китеп бара.

Ул изгелек, игелек эшләргә өлгерми яисә аз эшли. Якынын, туганын ныграк яратырга җитешми, табигать матурлыгын тиешенчә тоймый, әти-әнисенә, иренә яки хатынына җылысын биреп җиткерми, классикларның мәшһүр әсәрләре укылмыйча кала. Кеше караңгылыкны каһәрли, тик шәм генә булса да яндырып, шул караңгылыкны киметү турында уйламый. Ә вакыт туктый белми. Берзаман шундый көн җитә: кеше барысын да диярлек аңлый башлый. Тик кеше булырга гына инде соң була...

КАРА АЛТЫНЛЫ ЮЛ

Арабыздан беребез

ТАТАРСТАН НЕФТЕНӘ 80 ЕЛ

Сәясәттә дә, кара алтын табу өлкәсендә дә үз кеше ул. Һәр икесенең үсешенә аның саллы өлеше кергән. Күпләргә танылган дәүләт эшлеклесе, ТАССР Югары Советы президиумы рәисе Әнвәр Баһаветдиновның тормыш иптәше буларак та таныш ул. Сүзебез «Татнефть» оешмасының кадерле ветераны Наилә Баһаветдинова турында.

– Безнең балачак сугыш елларына туры килде. Унынчы сыйныфны тәмамлаган ел иде. Әтием Сталинград янындагы бәрелештә һәлак булды. Без – дүрт кыз, иң кечкенә сеңлемә ул чакта нибары ике яшь кенә иде. Әниемә булышырга кирәк. Шуңа күрә мине юллама белән Бөгелмәдәге НЧ-16 станциясенең кадрлар бүлегенә җибәрделәр. 19 яшемдә инде мине районның комсомол секретаре итеп куйдылар. 1951 елда партия мәктәбенә укырга киткәндә район башкарма комитеты рәисе урынбасары булып эшли идем, – дип искә ала ул елларны Наилә апа.

Шушы партия мәктәбендә насыйп ярын да очрата ул. Булачак ире Әнвәр Баһаветдинов белән ике ел буе бер өстәл янында утыра алар. Ул чакта Әнвәр әфәнденең Бондюг райкомының (хәзерге Менделеевск районы. – **Ред.**) икенче секретаре булып эшләгән чагы була.

– Укуны тәмамлагач, Казанда калырга тәкъдим иттеләр. Әмма мин, бөтен кешене гаҗәпкә калдырып, туган ягым Бөгелмәгә җибәрүләрен сорадым. Шул рәвешле Әнвәр белән икебезне Бөгелмәгә җибәрделәр. Мин – КПССның шәһәр комитетында эшли башладым. Әнвәрне партиянең район комитетына агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире итеп билгеләделәр, – ди Наилә ханым.

Күп тә үтми, яшь гаиләгә ямь өстәп кызлары Фәридә туа. 1950 нче еллар азагында партиянең район һәм шәһәр комитетларын берләштерәләр. Үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Әнвәр әфәнде белән Наилә ханым сайлау алдында кала: икесенең берсенә партия эшеннән китәргә кирәк була. Наилә ханым иренә юл бирә. Озакламый гаилә башлыгын беренче секретарь итеп Азнакайга эшкә күчерәләр. Наилә ханым исә «Азнакайнефть» идарәсенә килә.

Наилә Баһаветдинованың кара алтын тармагындагы юлы әнә шуннан башлана. «Азнакайнефть»тә башта кадрлар өчен җаваплы белгеч, аннары социаль-икътисадый исәп бүлеге җитәкчесе, хезмәт бүлеге башлыгы булып эшли ул. Соңрак Әлмәттә «Татнефтегаз» оешмасының баш икътисадчысы була.

– «Татнефть» оешкан чордан бирле республикада бик күп югары квалификацияле белгечләр, социаль хезмәт геройлары, бораулау, нефть табу осталары үсеп чыкты. Бер «Азнакайнефть» оешмасыннан гына Коми, Ингушетия, Белоруссия, Төрекмәнстанга күпме белгеч нефть тармагын җитәкләргә китте. Советлар Союзы нефть тармагының соңгы министры Лев Чурилов та хезмәт юлын Татарстанда – «Азнакайнефть» оешмасында башлаган. Гомумән, «Татнефть» оешмасы, республиканы гына түгел, оешмада эшләгән бик күпләрне эшле, ашлы итте, – ди ул.

Наилә ханым нефть тармагында эшләгән елларын яратып искә ала. 97 яшен тутырган димәссең дә: ул чорда булган һәр факт, мизгелне төгәл һәм аермачык хәтерли ул. Наилә Баһаветдинова – Әлмәттәге нефть институтына нигез салучыларның берсе дә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– «Татнефть» берләшмәсе Казанга күченгәч, «ТатНИПИнефть» оешты. Шул чакта кадрлар әзерләү бурычы килеп басты. Анда, нигездә, урта белемле кешеләр эшли иде. Казанга укырга керергә киткән җирдән баллары җитмәү аркасында кире районга әйләнеп кайткан балалар да бар иде. Әлмәтнең шәһәр комитеты сәркатибе Наилә Закировага шалтыратып: «Әйдә ике төркем оештырабыз», – дидем. Ул бу тәкъдимне күтәреп алды. 1957 еллар иде бу. Шул рәвешле ике шәһәрдә 25 кешелек ике төркем оештырдык. Әлмәттә нефть төркеме оешты. Бөгелмәдәге төркемне соңрак төзүчеләргә тапшырдылар, – дип искә ала Наилә ханым ул елларны.

Бүген Наилә Баһаветдинова кызы Фәридә (фотода), оныклары Булат, Мурад, Тимурның ихтирамын тоеп, кадерле әни, дәү әни булып яши. Кызы Фәридә – шулай ук бөтен гомерен кара алтын тармагына багышлаган шәхес, нефть тармагы ветераны. Бүген «Татнефть» ветераннар советының Казандагы бүлеген җитәкли. Фәридә Булгакованы күпләр «Нефть табу тарихы музее»на нигез салучы һәм оештыручы буларак та белә. Илкүләм яшь геологлар олимпиадасының Әлмәттә уза башлавы да – аның тырышлыгы нәтиҗәсе.

– Кырык ел гомеремне «Татнефть» компаниясенә багышладым. Ул елларымны сагынып, горурлык белән искә алам. «Татнефть» социаль юнәлештәге максатларны чынга ашыруга зур игътибар бирә. Хезмәткәрләренә күрсәтелгән игътибар ягыннан да аны үрнәк итеп куярлык. Бүген «Татнефть»нең көчле ветераннар оешмасы эшләп килә. Өлкәннәр һәрчак игътибар тоеп яши. Аларга ял йортларына бушлай юллама бирелә, мәдәни чараларда да актив катнашалар. Бәйрәм саен кадер-хөрмәт күрсәтелә. Минем карамакта – 250 кеше. Гел элемтәдә торабыз, – ди Фәридә Булгакова.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Белем һәм тәрбия

«АПА, ИСӘНМЕСЕЗ!»

ТҮБӘН КАМАНЫҢ 2 НЧЕ ТАТАР ГИМНАЗИЯСЕ НИЧЕК ЯШИ?

«Исәнмесез!» Каршыбызга атлаучы кыз баланың ерактан ук килгән тавышы шактый озын юлдан соң уятып җибәргәндәй булды. Аннан соң очраган һәр баланың шулай каршы алуы хәтта сәер тоелды. Шәһәр мәктәбенә кереп барабыз югыйсә. Баксаң, Түбән Каманың нәкъ үзәгендә урнашкан Бакый Урманче исемендәге 2 нче гимназиядә тәртипләр шундый икән. Монда «апа»-«абый»лар укыта, кыңгырау урынына татарча җырлар яңгырый, әле дә «Әлифба бәйрәме» уздырыла.

13 мең квадрат метр, хәтта артыграк та әле. Хәзерге вакытта җәмгысы 1233 бала әнә шундый киң һәм якты гимназиядә белем ала. 30 елдан соң тәүге тапкыр ремонт күреп, яңа сулыш белән «яши» башлаган бу белем йортына килеп керүгә, башка «минем дә монда укыйсым килә» дигән уй кереп оялый. Ул уйны гимназия буйлап йөргәндә күргән якты сыйныфлар, дүрт остаханә, шушы ук бинадагы сәнгать мәктәбе, өч спорт залы, ике бассейн, китапханә, 350 баланы бер тәнәфестә сыйдыра торган ашханә һәм тагын күп нәрсә ныгыта.

Төсләр. Гимназиядә хәтта төсләргә дә мәгънә салынган. «Ремонт ясаганда, дизайнерлар Бакый ага Урманченың картиналарын өйрәнеп, аларда өстенлек иткән төсләрне сайлап алды. Гимназиянең эчке бизәлешендә бары шул төсләр генә кулланылды», – дип аңлатты гимназия директоры Айгөл Гаязова.

Белем йорты буйлап йөргәндә игътибарны җәлеп иткән тагын бер нәрсә – диварлардагы язулар, рәсемнәр. Гимназиянең һәр каты билгеле бер темага багышланган. Әйтик, ватанпәрвәрлеккә багышланган каттагы диварда Дан орденының тулы кавалеры Рифкать Гайнуллин сурәте төшерелгән, егетлек, батырлык турындагы гыйбарәләр, шигырьләр язылган. Сәнгатькә багышланган катны исә татарның күренекле сәнгать эшлеклеләренең портретлары, җыр, моң, милләт турындагы канатлы сүзләр бизи. Айгөл Нильсон кызы сүзләре белән әйтсәк, монда һәр детальгә игътибар бирелгән.

Кыңгырау тавышы урынына татар җырлары куелу – шундый мөһим детальләрнең берсе. Укучыларны дәрескә озатып һәм дәрестән чыгаручы көйләр арасында «Ай, былбылым», «Туган як», Салих Сәйдәшев маршы, балалар үзләре сайлаган «Мин яратам сине, Татарстан» кебек җырлар бар.

– Без аларны сүзләре белән махсус куябыз. Башларына сеңсен, өйрәнсеннәр, дибез. Рус төркемнәрендә укучылар да җәмәгать транспортында яңгырый торган «Сак булыгыз, ишекләр ябыла» сүзләрен яттан белә бит, татар җырларын, димәк, әзме-күпме татар телен дә шулай өйрәнә алар. Бала вакытта «сеңдерсәләр», картайганчы онытмаячаклар, – ди Айгөл Гаязова.

Татарча тәрбия – гимназиянең төп максаты, юнәлеше. Без яңа гына атаганнар – тәрбия эшенең бер өлеше генә.

– Бездә дәресләр, уку-укыту эше ике телдә алып барылса, тәрбия эше – 100 процент татар телендә. Нәтиҗәсе күренә: татар спектакльләренә, концертларына йөрүчеләрнең, татарча газета-журналлар укучыларның күпчелеге – безнең балалар. Шәһәр күләмендә уздырылучы бәйгеләрдә, татар теле һәм әдәбиятыннан олимпиадаларда катнашучылар – безнекеләр. Узган уку елында 9 нчы сыйныфны тәмамлаган җиде бала татар теленнән имтихан бирде. Ел саен биреп торалар. Аларга бары үтемле итеп аңлатырга гына кирәк, – дип сөйләде Айгөл Нильсон кызы.

«Исәнмесез»гә әйләнеп кайтсак, балаларның ерактан ук шулай матур итеп исәнләшүе монда килгән кунакларны таң калдыра торган үзенчәлек икән. Укытучыларга да исем һәм әтисенең исеме белән эндәшү юк, барысы да – «апа», «абый»лар.

– Кайбер укытучыларның исемнәрен Соңгы кыңгырау бәйрәмендә генә белүчеләр дә бар. Электән килә бу традиция, очраган һәр кеше белән исәнләшү дә шулай. Бер бездәдер инде ул, хәзер бит авыл мәктәпләрендә дә «апа», «абый»лар аз калды, – ди гимназия директоры.

Әти-әниләр белән мөнәсәбәткә шулай ук аерым игътибар бирелә монда. Күбесе – шушы гимназияне тәмамлаган кешеләр. Шуңа балаларын кайда алып килгәннәрен яхшы беләләр.

– Һәрхәлдә, татар теленә, татарча тәрбиягә каршы чыккан бер генә әти-әни дә булмады. Башка мәсьәләләргә килгәндә, аларны тыңларга гына кирәк. Ул миңа гына – 1200 бала, алар өчен – бердәнбер бит ул, йөрәгеннән өзелеп төшкәне. Яныма килә икән, мин аны тыңларга, ничек кирәк, шулай ярдәм итәргә тиеш. Шуны аңламасаң, эшли алмыйсың, – ди Айгөл Гаязова.

Озак көткән ремонт эшләрен дә сабырлык белән кабул иткән әти-әниләр.

– Ремонт барган чакта уку туктап тормады. Шау-шу, тавышка да ияләндек. Физик тәрбия дәресләре коридорларда узды. Ләкин бер генә әти-әни дә, бер генә бала да: «Эх, авыр», – димәде, зарланмады. Шундый шартларда укып та, имтихан нәтиҗәләре әйбәт булды, химия фәненнән бер егетебез 100 балл җыйды, – ди гимназия директоры.

Ә **ремонт тарихы** шактый катлаулы була. Гимназияне төзекләндерү өчен ишекләрнең ачыгына да, ябыгына да шакырга туры килә...

– Биш еллап артыннан йөргәннән соң, ниһаять, ремонтны башладык. Үзәккә үтте ул, дөресен әйткәндә... Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтовның, фән һәм мәгариф министры Илсур Һадиуллинның, «Бердәм Россия» бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлеге Төбәк башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Лилия Әхмәтҗанованың, район башлыгы һәм шәһәр мэры Рамил Муллинның, Татар конгрессының Түбән Кама бүлеге җитәкчесе Рөстәм Ганиевның, татар җанлы шәһәрдәшләребез Хәмзә Баһмановның, Фирдәвес Хановның, Рафис Мостафинның, Васил Камаловның һәм башкаларның өлеше бик зур булды. Рамил Муллин ремонт дәверендә гимназиянең эчке биналарының дизайнын һәм төзелеш мәйданнарында ремонтның ничек баруын, билгеләнгән вакытка ремонт эшләре төгәлләнүне контрольдә тотты һәм укучы балаларның яңа уку елын яңартылган бинада каршы алулары өчен тырышты. Көтеп алган Белем көнен без шатланып, яңа, матур, төзек гимназия ишегалдында каршы алдык. 500 млн сумга якын акча китте ремонтка. Әле төгәлләнмәгән урыннары бар. Аларын да башкарып чыгарга язсын, – дип теләде Айгөл Гаязова.

Киләчәкне бүгеннән үк уйлап яши һәм эшли торган гимназиягә уңышлар гына телисе килә. Айгөл Нильсон кызы әйтмешли, авыл түгел, шәһәр балалары укый бит монда. Аларның шулай: «Апа, исәнмесез!» – дип сәламләве – без яши торган чор өчен үзе бер җиңү. «Милләтнең йөзек кашлары, татар зыялылары булсыннар дип тырышабыз. Вакытында тәрбияләмәсәң, соңга калуың бар», – ди гимназия директоры да.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

БИКҮЛЕГӘ КАЙТМАУ ИКЕЛЕ

СОҢГЫ ЕЛДА АВЫЛ ҮЗЕНӘ НЫГРАК ТАРТА

Нурлат

Бикүле авылы безне Татарстан әләме сурәте төшерелгән баганалары, «Иң үрнәк йорт» дигән язулары белән каршы алды. «Кунак йорты»на кадәр бар монда. Республикада беренчеләрдән булып үзара салым акчасына трактор алганнар. Гобәйдулиннар йортында хәтта үзйөрешле комбайнга кадәр саклана. Читтән гади генә булып тоелса да, урамнарыннан Бикүленең яңалыкка омтылуы күренә.

Сулыш яңарту

Бикүледә 225 йорт исәпләнә, шуның 189ында гына яшиләр. 453 кешесе бар. Узган ел 6 бала туса, быел – 3. Кайбер өйләрдә яшәмәсәләр да, ташландык җирләр юк. Бер генә йорт ябык. Шуңа да карамастан, барысы да бакчасына бәрәңгесен, яшелчәсен утырта.

Клубы, мәктәбе, кибете бар. Заманасында өч мәчете булган. 2010 елда кышын көчле җил чыгып, соңгы гыйбадәт йорты янып беткән. Тагын өч елдан ике катлы итеп яңасын төзегәннәр.

Узган ел Бикүле авылы «Авыл территорияләрен комплексы үстерү» программасында катнашып, грант откан. Шул акчага ял итү паркы төзеп, сәхнә куйганнар. Бәйрәмнәрдә тәмле ризыклар пешерү өчен мичене кадәр бар. Киләсе елга стадион ясамакчылар. Яңа ел чыршысын да шунда бизиләр икән. Моңа кадәр Бикүле авылы чыршы бизәү буенча районда ике ел рәттән беренче урынны алган. Авылда иң матур, үрнәк йортларны да билгеләгәннәр. Әнә Фәнүзә Сәлахова хуҗалыгы «Иң үрнәк йорт» дип табылган. Бакчасында 70тән артык төрле чәчәк үстерә икән. Чәчәкләр бәйгесендә беренче урынны яулаган.

Үзйөрешле комбайн турында Шамил Гобәйдуллин горурланып сөйләде.

Ә «Кунак йорты» кем өчен? Әллә монда туристларны җәлеп итмәкчеләрме? 2017 елда фермер Илшат Зәйнуллин, авылга кайтып, ташландык йортны алып, сарай төзегән. Анда 50 баш сыер тота. Ә кунак йортын эшчеләргә, туганнарына ял итү өчен салган ул. Бассейны да бар. Мал караучылар өйләренә юынып, ял итеп кайтып китә икән.

Бер сыйныфта – шәһәр баласы

– Соңгы ике елда авылга яшьләрнең, күпбалалы гаиләләрнең кайтуы күзәтелә. Берсенең алты баласы бар, тагын бер гаилә августта кайтты. 6 нчы сыйныф җитәкчесе: «Сыйныфымда барысы да – шәһәр баласы», – ди. Татар мәктәбе булса да, читтән кайтучылар аңласын өчен, русча сөйләшергә тырышалар. Хәзер авыл баласы болай да русча сөйләшә бит. Бер караганда, Нурлатка да якын тормыйбыз инде. Тугызъеллык мәктәп шулар хисабына яши әле, – ди Бикүле авыл җирлеге башлыгы Алсу Шакирова.

Авыл үз хезмәте белән яши. Җирләрне Сөләйманов крестьян-фермер хуҗалыгы эшкәртә икән. Халыкның пай җирләре барысы да – арендада. Юллар чистартумы, күпер салу, күл казытумы – барысын да үзидарә башкара. Авылның төзеклеген сакларга үзара салым акчасы да булыша. Быел кеше башыннан 2500әр сум җыйганнар. Киләсе елда 3 мең итмәкчеләр. Бирмим, дип киреләнүче юк, чөнки башкарган эшләре – күз алдында. 2017 елда шушы акчага трактор сатып алганнар. Таксистларның эшкә барасы бар дип, юлларны сәгать 5тә үк ачалар икән. Җирлек башлыгы әлеге вазыйфада –3 ел. Авылда очраган һәркем аңа тырышлыгы өчен рәхмәт укый.

Комбайн – әтисе истәлеге

Фәния һәм Шамил Гобәйдуллиннар биш ел элек туган нигезләренә күченеп кайткан. Балалары шәһәрдә яши. Гаилә башлыгы гомер буе Нурлат шәһәрендәге оешмада ташчы, нефть бораулаучы булып эшләгән. Хәзер инде икесе дә – лаеклы ялда.

Фәния ханым – Иглай авылыннан. Мәрхүм каенанасы Мәрзия: «Кайтмасагыз, йортны дача итеп булса да тотарсыз, нигезне ташламагыз», – дигән. Аның васыятен истә тотып, төп йортка кайткан алар. «Үтәмичә ярамый, әни шулай кушты», – ди хуҗабикә, кырт кисеп. Бар җирне яңартып, матур гына яшәп яталар. Фәния апа җәй көне чәчәкләр үстерә. Шамил абыйның шөгыле – мич чыгару. 18 яшеннән үк белә ул бу эшне. Чирмешән буена барып, үзле балчык иләп алып кайта. Сыйфатлы булсын дип тырышуы. Кемгәдер мичнең – шашлык, пицца, кемгәдер ипи пешерә торганы кирәк. Авыл паркындагы мич – аның хезмәте. Шамил абый буш вакытында әтисеннән калган «Таганрог» тракторын иярли. Аның белән авылдашларына черемә, балчык ташый.

Үзйөрешле комбайн дип йөртәләр аны. Авылда гына түгел, хәзер республикада да юктыр ул. 1969 елгы техника булса да, үз эшен яхшы башкара икән.

Кичке ял

Алсу Шакирова – авыл урамнарына гармун моңнарын кайтаручы, әби-бабайларның күңелен җилкендерүче дә әле. «Җәйге капка төбе» проектын башлап җибәргән алар. «Бикүле пятачогы» дип йөртәләр аны. Һәр атна саен авылның бер урамында мәдәният хезмәткәрләре белән бергәләп кич утыруны оештырганнар. Күршеләр, җыелышып, кызыклы хәлләрне искә төшерә. Гармунын тартып җырлый, бии. Хуҗалар, ишегалдын бизәп, табын корып, кайнар чәй, коймак белән сыйлый. Үз күңелеңне күтәрмәсәң, тагын кем күтәрсен? Менә шулай күңел ача да белә бикүлеләр.

Сәрия МИФТАХОВА

РОМАНОВ КҮПЕРЕ

Без бел(мә)гән тарих

Казан – Мәскәү поездына утырып, башкалабыз тарафына юл тотмаган кеше сирәктер, мөгаен. Тирә-яктагы табигатьнең гүзәллегенә хозурланып барганда, Яшел Үзән шәһәре янында Идел ярларын тоташтырган Романов күперенең нинди мөһим корылма булуы турында белүчеләр, уйланучылар бармы икән?

Булса да, еллар үткән саен кимидер. Ни дисәң дә, хәзер самолетта очарга да мөмкинлек ачылды, машинада җилдерүчеләр дә күбәйде. Өстәвенә Зөя аша да күпер салынды, М12 трассасында яңасы да төзелә. Ә шул ук вакытта быел 110 еллыгын «бәйрәм итүче» күпернең тарихы бик кызыклы да, фаҗигале дә. Ул бүген дә мөһимлеген югалтмаган. Тарихчы журналист **Рәис МИҢНУЛЛИН** белән без шул хакта сөйләштек.

:: Рәис Мәрданович, күпер тарихы белән ни сәбәпле кызыксынып киттегез? Шактый гына материаллар да туплагансыз.

– Бу хәл Габдулла Тукай тормышына бәйле дисәм, ышанмассыз да инде. Эш болай булды. Шулай бервакыт шагыйрьнең Казандагы музеена килеп чыккач, фәнни хезмәткәр Әлфия Шәрипова белән сөйләшеп киттек. Әхмәт Фәйзинең «Тукай» романында бик кызыклы очрак сурәтләнгән икән. Ятим калган Габдулла Казанга килгәч, Печән базарындагы Мөхәммәтҗан исемле кырыктартмачыдан мондый вакыйга турында ишетә (бу хакта шәһәр Думасында губернатор үзе сөйләгән була). Имеш, патша галиҗәнаплары Сәгыйть бай Сәгыйтовны үз янына Петербургка чакыра икән. Ул вакытта барлык илләрнең диярлек осталарына патша атланып йөри торган атка иң яхшы ияр ясарга заказ бирелә. Төрле дәүләтләрдән күргәзмәгә ун мең тирәсе ияр алып киләләр. Патша икесен генә сайлап ала: Алман иленнән килгәнен һәм Сәгыйть бай теккәнен. Министрларын җыя да, кайсына – чуен, кайсына алтын медаль бирергә икәнлеген тәгаенләргә куша. Министрлар берсүзсез, Сәгыйтовка алтынын бирергә кирәк, дип тәкъдим итәләр. Шулвакыт патша, имеш, болай дигән: «Мондый ияр өчен алтын медаль генә аз. Казаннан Петербургка кадәр тимер юл салсыннар, кенәз шул юл буйлап кунакка килсен». Күпер тарихына кереп китәр өчен миңа шушы очрак җитә калды. Күбрәк белү өчен Яшел Үзәндәге төбәк музеена юл тоттым. Анда экспонатлар бик күп. Әмма кырыктартмачы сөйләгәннәр дөреслеккә нигезләнгәнме, әллә уйдырмамы – бу хакта документлар юк.

:: Шунысы кызык: Казан губернасында күпер төзелгәнче үк тимер юл булган бит. Ул Мәскәүдән Шихран (Канаш) аша Түбән Карамалы бистәсенә кадәр килгән. Ә бу якта поездлар Казан белән Паратск (хәзерге Яшел Үзән территориясе) арасында йөргән. Күпер төзү эшенә ник соңлап кына керешкәннәр?

– Тимер юл, чыннан да, 1894 елда ук сафка баса. Әмма Идел аша күпер салынмый. Чөнки юлда очраган кечкенә елгалар аша агач күперләр генә салырга рөхсәт бирәләр. Тимер күперләр турында сүз бөтенләй булмый. Ә зур елгаларны урап узарга кушалар. Өстәвенә, Мәскәү – Казан тимер юлы акционерлар акчасына төзелү сәбәпле, юл хуҗалары акча эшләү ниятеннән төрле хәйләләр уйлап табалар. Идел аша йөк ташу тарифка керми, аның өчен пассажирлардан да, багаж өчен дә аерым түләү карала. Шул сәбәпле бу кичү чын мәгънәсендә алтынга тиң була. Җәмгыять бик зур керем ала. Әмма җәй көне пароходка, кыш көне боз өстенә куелган рельслар буенча баручы атлы чаналарга көйләнгән кичү «бүселә» башлый. Боз киткәндә исә эш бөтенләй туктала. Тау кебек өелгән товар атналар буена елга буенда аунап ята. Хуҗалары үз әйберләрен таба алмый интегә. Шул сәбәпле, югарыга бертуктаусыз шикаятьләр агыла. 1902 елда Николай IIнең күпер салу турындагы карары чыгуга карамастан, төрле сәбәпләр белән төзелеш ун елга тоткарлана әле. Юл министрлыгына 11 проект тәкъдим ителә. Ахыр чиктә рус күпер төзү мәктәбенә нигез салучы Николай Белелбюбский проектын сайлап алалар. 1911 елның гыйнвар аенда күпер, ниһаять, төзелә башлый.


Күпер күренеше. 1913 ел.

:: Мин үзем дә шушы күпердән ерак түгел, Яшел Үзән районы авылында туып үстем. Без бәләкәй чакта әби-бабайлар «чуен юл» турында бик гаҗәпләнеп тә, сокланып та сөйлиләр иде. Бу күперне төзегәндә коточкыч фаҗигаләр булган дип тә ишеткәнем бар...

– Төзелештә 3 меңгә якын эшче булган дигән документлар бар. Ачлыктан тилмергән ярлы-ябагайның азрак булса да акча эшлисе, тормышын җайлап җибәрәсе килә. Әмма хыяллары чынга ашмый. Шартлар авыр, ашарга юк, халык төрле авырулардан кырыла. Бу хәлгә подрядчыларның гына исе китми. Юкка чыкканнары урынына ташкын булып килеп торалар бит. Акча да күп сорамыйлар. Шуңа күрә куркынычсызлык кагыйдәләренә төкереп кенә карыйлар. Ә моңа кадәр күрелмәгән фаҗигаләр кабатланып кына тора. 2011 елның көзендә көннәр бик тиз салкынаеп китә, елгага боз ката. Әмма бераздан җылытып җибәрә. Су күтәрелеп, боз кузгала һәм терәкләр янындагы агач басмаларны сындыра. Эшне тиз арада туктатырга кирәк була. Әмма моны кирәксенмиләр. Нәтиҗәдә 200дән артык эшче суга чума һәм һәлак була. Ни кызганыч, бу хәл беренче смена кайтып китмәгән, ә икенче сменаның эшкә килгән чагына туры килә. Шуңа күрә корбаннар саны да күп. Кемнәр икәнлеге генә билгесез, чөнки монда эшләүчеләрне теркәп торуны кирәк дип тә тапмаганнар. Бу җәһәттән «Мы – волжане» дигән китапта мондый юллар бар: «Администрация елга «йоткан» төзелеш материаллары өчен борчыла. Яз көне водолазлар яллыйлар. Берсен төшерәләр, минут та үтми, ул үзен өскә күтәрергә сигнал бирә. Чыкканда авыр хәлдә була. Аңына килгәч: «Су төбенә төшүем булды, миңа таба, кочакларын җәеп, бер кеше килә башлады», – дип сөйли. Аңа ышанмыйлар. Икенче водолазны төшерәләр. Ул түбәндәгеләрне хәбәр итә. «Су төбендә, чыннан да, кеше «басып тора». Аның аякларын таш баскан, куллары агым юнәлешендә тирбәлә, нәкъ каршыга килгән кебек хис туа. Тирә-якта цемент, таш, мичкәләр аунап ята, төрле яктан үлгән кешеләрнең кул-аяклары, башлары күренеп тора». Ә икенче елны яз көнендә, материалларны янга калдыру сәбәпле, күтәртелгән дамбалар торыклар һәм эшчеләр белән бергә агып китә. Алга китеп шуны да әйтик: күпер төзегәндә су режимы тупас бозыла, шуңа күрә соңрак та аварияләр күп була. Сусаклагыч төзелеп, су агымының тизлеге кимегәннән соң гына фаҗигаләргә чик куела.

:: Күпергә ни өчен Романов исеме бирелә? Халык бу исемне телгә алмый иде. Һәрхәлдә, авыл кешеләреннән ишеткәнем булмады.

– Әле күпер проектланганда ук, Казан морзалары, Романов династиясенең 300 еллыгы хөрмәтенә дип, Николай IIгә шундый үтенеч белән чыгалар. Император ризалаша. Күпернең тантаналы ачылышына бик күп кунаклар килә. Шул хөрмәткә Олы Карамалы авылында архитектор Щусев проекты буенча часовняга нигез салына.

:: Күпернең алга таба язмышы нинди?

– Гражданнар сугышы вакытында яр буендагы торыкларның дугасыман ясалган таш аркаларын шартлаталар. Ремонт эшләре вакытында аларны металлга алыштыралар. 1955 елда бер юллы Романов күпере янәшәсенә икенчесен салалар. Алар бер-берсеннән бик нык аерыла. Искесендәге торыклар беркеткечләр белән тоташтырылган, яңасында эретеп ябыштырылган. 2006 елда иске күпернең торыкларын алыштыра башлыйлар, 2011 елда бу эш тәмамлана. Шунысы хак: нинди генә юллар, күперләр төзелсә дә, Романов күпере үзенең мөһимлеген бүген дә югалтмый.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Соклану

Хуҗабикә

Хатын-кызны «хуҗабикә», «сугышчы», «приз», «муза» дигән социаль төрләргә бүлеп карау бар. Сыйныфташым Гөлназ белән сөйләшкәннән соң, һич икеләнүсез аны беренче төркемгә керттем мин: хуҗабикә!

Кайда нинди тәмле ризык күрсә, шуны пешереп, гаиләсен сыйларга тырыша. Чигү, тегү кебек кул эшләрен ярата. «Минем эшем дә шундый бит: бәйрәмнәр, уеннар, бәйгеләр өчен төрле әйберләр ясарга туры килә. Хәзер бит нинди генә материал юк, интернетта нәрсә генә ясарга өйрәтмиләр! Ул материаллар белән үзеннән-үзе матур әйберләр тудырасың. Бәйрәмнәргә музыка залын бизәргә яратам. Чәчәкләр үстерергә яратам. Иң яраткан чәчәгем – георгин (дәлия), аның бик күп төрләрен үстерәм», – ди ул. Әйтәм ич, «хуҗабикә» кайда гына булса да, аның янында җылы, тәмле, матур, якты!

Гөлназ безнең күрше авылга – Шахмайга киявгә чыгып, Гарифуллина фамилиясе алып, өч бала үстерде, хәзер инде оныклар сөя. Беркайчан да шәһәргә кызыкмадым, ди. «Укыган чакта да атна саен авылымны сагынып кайта идем. Була бит инде ул шундый кешеләр. Шәһәргә кунакка барырга гына яратам. Шәһәрдә миңа иркенлек җитми». Әйе, табигатькә якын кешегә шәһәр кысан инде ул. «Шәһәрдә кеше бер-берсенә битараф, ә авылда «кеше нәрсә әйтер, күрше нәрсә әйтер» дигән әйбер бар әле һәм ул зур көчкә ия. Авылда син бөтен кеше күз алдында, «кешедән яхшы түгел» дигән уй ул – бер-береңә ихтирам бит инде. Шунысы да күңелгә якын».

Гөлназ кебек кешеләрне Җирнең кояшлы ягында яшәүчеләр, дим мин. Кыекны күргәнче, турыны тизрәк күреп өлгерә ул. «Хәзер авылда да шәһәрдәгедән ким яшәмибез, Аллага шөкер, бөтен нәрсәбез бар, – дип сөенә. – Бүгенге авыллар бик матур, бик төзек. Һәр йорт үзенчә матур. Капка төпләрендә төзелеш әйберләре, кирәк-ярак тоту юк хәзер. Авыл халкы да нык тырыш. Тормыш авыр дисәк тә, һәрбер авырлыкка яраклаша кеше. Төрле юлларын табып, яшәешен үзенә уңайлы итеп кора. Дөрес, күмәк хуҗалыклар юк хәзер, әллә никадәр кешегә эш калмады. Күп кеше Яңа Чишмәгә йөреп эшли, Алексеевск юл төзелеше филиалында, нефть оешмаларында эш бар. Хәзер Шахмайда кече фермерлык хуҗалыклары бар, алар елдан-ел арта. Кем сыерлар, кем үгезләр тота, кем җир эшкәртә...»

Шахмайда яшьләр дә чагыштырмача күп кала. Урта мәктәпкә өч авылдан – Чаллы Башы, Чертуш, Акъярдан килеп укыйлар. Яңарак кына берничә йорт салып кергән яшьләр дә, йорт салып ятучылар да бар икән. Балалар бакчасына унҗиде бала йөреп тора, ун бала бакча яшенә җитеп килә. Әле туачак балалар да бар.

«Яшьләр күпләп дин юлына баса бездә. Мәчетләребез һәрвакыт тулы», – ди Гөлназ. Иманлы яшьләрдән иманлы балалар туар дип ышанасы килә. Чөнки... авыллар барыбер без үскәндәгечә түгел инде ул. Дистә еллар балалар бакчасында тәрбияче булып эшләгән кешегә ул балалар дөньясы аша күренә. «Хәзер татар авылының йөзен гаджетлы, русча сөйләшеп йөрүче балалар да үзгәртә. Безне әти-әниләр, абый-апалар урамнан эзләп алып керәләр иде, хәзерге балалар урамда уйнауны онытып бара, кулларында – телефон. Алар интернет геройларының, популяр блогер, мультфильм персонажларының исемнәрен белә һәм алар теле белән, алар сүзләре белән сөйләшә. Балалар бакчасында шул хәл белән көрәшеп гаҗиз булабыз, ләкин нәтиҗәсе зур түгел», – дип борчыла сыйныфташым. Балаларны төрле чараларга тарту юлы белән генә телефонлы чит дөньядан аерып була дип саный ул. Шахмайда Мирхәйдәр Фәйзи исемендәге музей эшләп килү дә бу проблеманы хәл итүдә бер ярдәмче булып тора икән. «Анда Гөлүсә Баһаветдинова дигән кызыбыз эшли, атна саен берничә чара үткәрә. Бакча балалары, мәктәп укучылары һәрвакыт кунак та, катнашучы да анда», – дип сокланып сөйли Гөлназ. Милли бәйрәмнәр оештыру, гореф-гадәтләрне өйрәтүне дә үтемле чаралар, ди.

Тыйнак, кечелекле, кешелекле ана, ир хатынын тагын ниләр борчыймы? Үз авылыбыздагы (Чаллы Башы) мәктәпнең бетүе, яшьләр калмавы борчый. Илләрнең тыныч булмавы борчый. «Үземнең улым да, кияү, оныкларым да бар. Аларның киләчәге өчен борчылып, куркып торам. Без матур тормышта яшәдек (болай дию әбиләрчә була инде), яшисе дә яшисе әле, әлбәттә; ә балалар өчен борчылам. Заманалар тыныч түгел, билгесезлек куркыта.

Без коммунизм диеп, якты маяклар куеп, яхшы тормышка өметләнеп яшәгәнбез. Хәзер мөмкинлекләр иксез-чиксез, бернәрсәгә мохтаҗлык юк, менә шул мохтаҗлык булмау ниндидер битарафлык китереп чыгара. Балалар әйбер кадерен белми, саклап тотмый. Ватылса, яңаны алып бирә ата-ана. Балаларның аз эшләве дә борчый: аларга эш аз хәзер. Су ташу юк, утын кисү юк, элементар гади эшләр юк.

Балалар китап укырга яратмый хәзер, шул да борчый. Мин үзем китапның исен исни-исни укырга яратам».

Курку-шөбһәләрен, борчуларын яхшыга өметләнүе белән кысрыклап чыгара ул һәм авылларның яшәргә, авырлыкларга бирешмәскә тырышуына шатланып яши. Шунсыз булмый. Ул бит – йортта җылы учакны саклаучы, димәк, авылның да яшәвенә өлеш кертүче.

Лилия ФӘТТАХОВА

Җәһәт әңгәмә

АМЕЛИЯ НИГЪМӘТУЛЛИНА:

«БЕР ТАТАР СҮЗЕ БУЛСА ДА КЫСТЫРАМ»

Казан кызы Амелия Нигъмәтуллинаны «Шаян ТВ» телеканалыннан карап, ул тавышландырган мультфильм-сериаллардан ишетеп беләбез. Күптән түгел Амелия мәктәп укучыларының «Татар кызы – 2023» шәһәр бәйгесендә җиңү яулады. Журналист булам, дип тәвәккәлләгән максатчан кыз нинди уй-хыяллар белән яши икән? Без әнә шуны белештек.

tatar-inform.ru

:: Өч ел элек газетага биргән әңгәмәдә: «Журналист булырга хыялланам», – дигәнсең. Тиздән мәктәпне тәмамлап, олы тормышка аяк басачаксың. Теләгең үзгәрмәдеме?

– Мин һаман да журналист булырга хыялланам. Хәзерге эшчәнлегем миңа бик ошый һәм аны дәвам итәсем килә. Кешеләр белән аралашу, яңа танышулар һәм яңа белемнәр туплаудан башка тора алмыйм.

:: «Татар кызы» бәйгесендә нинди сыйфатларың сине җиңүче итте дип уйлыйсың?

– Иң элек кешеләр йөзеңә карый. Елмаеп, балкып торсаң, игътибарны җәлеп итәсең. Шулай ук харизма, энергия җиңүгә этәрде дип саныйм. «Татар кызы» – матурлык бәйгесе генә түгел. Монда беренче чиратта татар телен, татар тарихын һәм милли гореф-гадәтләрне белү мөһим.

:: Бәйгедә үзеңне тулысынча күрсәтә алдым дип саныйсыңмы?

– Бер бәйге кысасында үзеңне тулысынча күрсәтеп бетереп булмыйдыр ул. Үземне 100 процентка ачылдым дип санамыйм. Әле тагын да яхшырак булдыра алам.

:: Шәһәр кызы булуга карамастан, татарча камил сөйләшәсең. Хәзер яшьләр арасында бу – сирәк күренеш.

– Мин гаиләмдә дә, дусларым белән дә татарча сөйләшәм. Гимназиядә бөтен дәресләр татар телендә алып барыла. Һәм, гомумән, минем янымда булган кешеләр бөтенесе диярлек татарча сөйләшәләр. Татарча белмәгән танышларым бик сирәк. Гадәти тормышта, урамда чит кеше миннән берәр нәрсә килеп сораса, татарча сүз кыстырмыйча, җавап кайтармыйм. Хәтта ул кеше мине аңламаса да. Үзеннән-үзе шулай килеп чыга.

:: Син бит әле – дубляж актеры да. Геройларны тавышландыруда синең өчен иң авыры һәм иң кызыгы нәрсә?

– Җөмләләр билгеле бер вакыт аралыгына сыймаса, тизрәк әйтергә кирәк. Андый вакытларда кайбер хәрефләр «сызгыра», бу турыда онытмаска, игътибар белән тыңларга кирәк. Иң кызыгы ул – озак итеп көлү, әйтик, бик усал йә кечкенә кырмыска кебек кычкыру. Бу эштә иң мөһиме – персонажны тою, үзеңне аның урынына куя белү, гомумән, аның тормышы белән яшәү. Шулай ук дикция, сүзләрне дөрес басым белән әйтү мөһим.

Мультфильмнар тавышландырганда күбрәк уйнарга, ә инде сериалларда чын тормыштагы кебек сөйләшергә кирәк.

:: Замана татар баласы нинди ул? Аны нәрсә белән кызыктырып була?

– Һәрберебез төрле, ләкин күбебез яңаны, әле билгесез булганны белергә омтыла. Шуңа үзебезне яңа өлкәләрдә сынап карыйбыз.

:: Синең күзаллавыңча, нинди ул асыл татар кызы?

– Минемчә, чын татар кызы тыйнак, сәләтле, мәрхәмәтле, һәрвакыт булышырга әзер һәм позитив.

:: Синеңчә, иң зур проблема нинди?

– Татар телендә аралашучылар азая, тел чүпләнә, йотыла, онытыла… Шуңа бик борчылам. Туган телебезне популярлаштырасы, үстерәсе иде. Һәркем кулыннан килгәнне эшләсә, өмет бар әле. Шул ук «Татар кызы», «Татар егете» кебек бәйгеләр дә моңа ярдәм итә.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Амелия турында белешмә

- 16 яшь, Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясендә укый.
- «Шаян ТВ» каналы һәм «Балачак җыры» концертларының алып баручысы, дубляж актёры.
- 2 нче гимназиянең «Гөлкәйләр» ансамблендә җырлый, спорт белән шөгыльләнә, йөзүгә йөри.

ТЕАТР ӘНИСЕ

КАЗАНДА ЛЕГЕНДАР АРТИСТКА ИСЛАМИЯ МӘХМҮТОВАНЫ ИСКӘ АЛДЫЛАР

Искә алу

«Кыр казлары артыннан биеклеккә тартылам…» Шушы җыры белән халык күңеленә мәңгелеккә кереп калды ул. Театр сәнгатендә якты йолдыз булып кабынган киңкырлы шәхес, көрәшче рухлы актриса, халкыбызның сөйкемле сөяге. Исән булса, 1 декабрьдә Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Исламия Мәхмүтовага 80 яшь тулган булыр иде.

Тинчурин театрын – ансыз, Исламия Мәхмүтованы театрсыз күз алдына китереп тә булмый. Алар бер-берсеннән аерылгысыз сыман. Исламия Мәхмүтова театрның бер эпохасы иде. Арабызда булмаса да, биредә аның рухы яши. 50 елдан артык гомерен багышлаган Кәрим Тинчурин театрында Исламия Мәхмүтованы искә алдылар. Без исә легендар артистка турында якыннарының истәлекләрен барладык.

Искә алу кичәсендә яшь Исламияне – талантлы актриса Резеда Сәлахова, олыгайган вакытын кызы Лилия Мәхмүтова уйнады. Бу очраклы да түгел кебек. Лилия Мәхмүтованы еш кына Исламия апаны хәтерләтә, диләр. Чыннан да, әнисенең чалымнарын шулай үтемле итеп ул гына күрсәтә ала торгандыр.

– Олыгайган саен, Исламиягә охшый барасың, дип әйтәләр. Әни күпкырлы талант иясе иде. Җырласа – күңелләрне айкап җырлады, сөйләсә – бәгырьгә үтәрлек итеп сөйләде, спектакль куям дисә – куйды. Әни театрга 56 ел гомерен багышлады. «Кыр казлары артыннан» спектаклендәге Ясминә роле белән халыкныкы булды. Әни Равил абый Тумашевка үпкәләп тә йөргән булган әле. «Нишләп 35 яшемдә 55 яшьлек хатын роле бирдегез?» – дигәч, Равил абый: «Исламия, бер дә борчылма, наным, ул синең иң яраткан һәм иң танылган ролең булачак», – дип әйткән. Һәм чыннан да, күпме рольләр уйнаса да, аны барыбер шушы Ясминә роле белән таныйлар, кайда гына булса да, «Кыр казлары артыннан» җырын җырлавын сорыйлар иде, – ди Лилия Мәхмүтова. – Әнинең «Күрәсем килгән иде», «Син бит – минем бергенәм», «Мәхәббәт чишмәсе»ндә махсус минем өчен язылган рольләр бар. Ул кешенең характерын аңлатып бирә ала торган иде. Һәрбер артистка аерым күзаллап яза торган иде. Әни кунакчыл хуҗабикә, оста бәйләүче дә иде. Гастрольләрдә күп йөргәч, шәл бәйләргә өйрәнде. Әтидән рамнар ясатып, аңа тарттырып, зур-зур «паутинка»лар бәйли торган иде. Минем өйдә әнинең үзе бәйләгән күлмәге дә бар. Аны башта үзе киеп йөрде, театр училищесына укырга кергәч, мин кидем. Барысын да күргәзмәгә куярлык! Якты кеше иде әни. Урыны оҗмахта булсын.

«Мин бәхетле бала булдым». Исламия һәм Хәлил Мәхмүтовларның кызы, Татарстанның атказанган артисты Ләйсән Мәхмүтова шулай диде.

– Әни гомер буе һәм соңгы сулышына кадәр театр дип яшәде. Үзен сәхнәсез күз алдына да китерә алмый иде. Хәзер әни булмаса да, аның рухы монда, безнең белән яши. Халык әнине бик сагына. Аны искә алалар, җылы хатирәләре белән бүлешәләр. Репетицияләрдә еларлык дәрәҗәгә җиттем. Артистлар да ашкынып-ашкынып эшләделәр, барысы да тырышты. Шаккатып карап тордым. Әни театрдан китмәде. Театр гел аның күңелендә иде. Моннан китеп буламыни? Ул бит монда яшь чактан бирле соңгы көннәренә кадәр булды. Аңа килделәр, хәлләрен дә белештеләр. Әни үзе дә театрга кереп чыга иде һәм шул чакта җанына рәхәт булып китә иде. Артистлар белән аралашкач, рухы күтәрелә иде. Театрны берничек тә артистның күңеленнән, тормышыннан алып атып булмый. Ул барыбер анда калачак, – дип сөйләде Ләйсән. – Мин кечкенәдән әни мәхәббәтен тоеп яшәдем, апама андый бәхет бик тәтемәде. Чөнки ул аны бәләкәй чакта аз күрде. Олыгайгач, бу театр барлыкка килеп, алар стационарда эшли башлагач кына әни күбрәк өйдә була башлады. Ә мин алар белән кечкенә чакта гастрольләргә дә чыгып йөрдем. Ул яктан мин бәхетле бала булдым.

Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Рузия Мотыйгуллина апасы Исламия белән мөнәсәбәтләре турында: «Гомер буе апа-сеңел булып яшәдек», – диде.

– Бер-беребезгә терәк-таяныч булдык. Ул минем апам гына түгел, киңәшчем дә, ярдәмчем дә, әтием дә, әнием дә булды. Исламия апа татар театрының тарихына зур шәхес булып керде. Әлбәттә, ул безнең нәсел өчен бик зур горурлык иде. Исламия апа бик хыялый кеше иде. Хыялланырга яратты. Ул бервакытта да бүгенге көн белән генә яшәмәде, бер-ике елга алдан планнар төзергә ярата иде. Кызганыч, әле аның бик күп эшләнмәгән эшләре калды. Соңгы вакытта ул язылып бетмәгән сәхнә әсәрен язып бетереп, сәхнәгә кую турында хыялланып, янып-көеп йөрде. Исламия апа бүгенге олуг бәйрәмендә үзе чыкса, үзенең балачагы, үсмер чагы турында искитәрлек, күңелләргә үтәрлек итеп сөйләр иде. Ул телгә, юморга бай булуы, үзенең эчкерсезлеге белән тамашачының күңелен яулады. Әни сөйләве буенча, Исламия апа бик шаян, шундый елгыр булган. Башкалардан аерылып торган кыз бала дип искә ала иде. Менә шушы әти-әни, гаилә канаты астында үскән матур чакларны искә төшерәм дә, күңелгә җылы булып китә. Шушы матур мизгелләр мине гомерем буе озата барды. Рәхмәт, апа!



«Олыгайган саен, әниемә охшый барам», – ди Лилия Мәхмүтова.

Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Марсель Җаббаров Исламия Мәхмүтова белән театрга бина яуларга барган вакытларын искә алды. Боларны сөйләү бер дә җиңел түгел иде аңа. Легендар артистның тамагына төер утырды, күзләренә яшьләр тыгылды.

– Бу сәхнәдән киткәнемә инде 20 ел булды. Бик сагындым. Әле дә хәтердә: Камал театры Горький урамыннан Татарстан урамындагы хәзерге биналарына күчкәч, без, алты артист, Мәскәүгә, СССР Мәдәният министрлыгына юл тоттык. Мактау кәгазьләрен, нәрсә бар – бөтенесен тутырдык та киттек. Безне күргәч, тегеләрнең күзләре шакмак булды. Делегация дигән сүзне ишеткәннәре дә булмаган аларның. Гадәттә, артистлар берәм-берәм, фатир, лаеклы исем, грамота сорарга килә. Без зур чемоданнар белән алты кеше басып торабыз. Ильичева атлы җайлы гына ханым кабул итте безне. Шунда Исламия әйтеп куйды: «Марсель Җәббартәре, сөйлә дә сөйлә син, бертуктаусыз. Без утын гына өстәп торырбыз», – ди. Шулай бөтен зарларны сөйләдек. Ильичева атлы ханым безгә өмет бирде. Канатланып, юләрләнеп, шашып чыктык без аннан. Кем җырлый, кем көлә, Исламия биергә тотынды. «Җәббартәре, булдырдык бит малай, җиңдек!» – ди. Казанга кайтуга, безне үзебезнең Мәдәният министрлыгында көтәләр иде. Шулай, озакка сузмыйча, кечкенә генә театр төзи дә башладылар. Минем белән барган биш кешенең берсе дә юк хәзер. Аларның якты истәлеге, хатирәсе мәңге саклансын.

Ләйсән САФИНА

«АЛТЫН» ЙОЛДЫЗЛАР

bolgarradio.com

Милли премия

Буйдак җырчыларны кем өшкерергә тиеш? Татарны нәрсә татар итә? Татар эстрадасының легендасы – кем ул? Быел «Болгар радиосы» Милли музыкаль премиясендә әнә шул һәм башка сорауларга җавап эзләп карадык.

Иске яңаны саклый...мы?

Машина да кабынудан баш тартып тилмерткән салкын кичтә бар халык «Пирамида»да иде диярсең. Кеше агыла торды, «Мирас» ансамбле «Болгар радиосы» алып баручылары белән бергә, килгән-кергәнне җырлатып һәм биетеп, тамаша залына озата торды. Шулай итеп, тәнәфес белән бергә дүрт сәгать барган тантанага җырлый-җырлый кереп утырдык.

Быелгы премиягә үзгәрешләр кертеләчәген белгәч, аеруча зур кызыксыну белән килгән идек. Бу юлы сценарийны яңа автор – Альберт Шакиров язган булса, тантананың яңа режиссеры Марсель Мәхмүтов иде. Соңгы арада күп кенә саллы тамашаларны оештыручы тандем. Караган кеше килешер: быел сценарий һәм башкасыннан алданрак күзгә ташланган төп үзгәреш сәхнә бизәлеше (бу очракта – экран) һәм ут булды. Алар җырчыларның чыгышларын да бер башка югарырак күтәрде, дисәк, арттыру булмас.

Премияне сез һәм без белгән кешеләр – Илфар Кәримов, Рөстәм Гайзуллин һәм Айгөл Хәйруллина алып барды. Илфар Кәримовның «Болгар радиосы»ның башкарма директоры икәнен беләсездер. Шуңадырмы, быел да алып баручылар арасындагы төрттерүләр, диалогларның күбесе «Илфар Илдусович» дип башланды. Бу трио – чыннан да, премиянең алыштыргысыз, аерылгысыз бер өлеше. Әмма аны ел саен караучылар яңарак төрле мәзәкләр, моңарчы ишетелмәгән диалоглар көтә бит.

Әйтик, өшкерү үзәге турындагы кебек. Рөстәм Гайзуллин, буйдакларга күз тию, аларның киемнәреннән энә ише нәрсәләр чыгу сәбәпле, әнә шундый үзәк ачарга тәкъдим итте. Моныңише актуаль темалардан җырлы гаиләләрнең күп булуы, мәхәббәт темасына артык еш җырлаулары, җырларның атамаларында охшашлык та телгә алынды. Кыскасы, ел дәвамында халык телендә булган вакыйгаларга үзенә күрә күзәтү ясалды.

Рух

Ләкин Милли музыкаль премиянең асылы – уен-көлке түгел, билгеле. Тантананың башыннан ахырына кадәр ике буын вәкиле – Татарстанның халык артисты Әсхәт Хисмәт һәм, кечкенә булса да, «Шахта», «Әрем исе, әрем тәме» җырларының һәм сүзен үтемле итеп башкаручы Рөстәм Хөсәенов бер мөһим сорауга җавап эзләде. Миллилек нидә чагыла? Беренче карашка милли булып тоелмаган премияне нәрсә яки кем милли итә? Ахырда нинди нәтиҗәгә килгәннәрен әйтсәк, бөтенләй дә интрига калмас. 1 гыйнварда «ТНВ» телеканалында әлеге премиянең телевизион версиясен карыйсы була бит әле.

«Иң...», «Иң...», «Иң...»

Премияне премия иткән җырчыларга да килеп җиттек. Быел җәмгысы 30 номинациядә җиңүчеләрне бүләкләделәр. Махсус кунаклар – Әсхәт Хисмәт белән Рөстәм Хөсәенов һәм Татьяна Ефремова чыгышларын кушып санасаң, 32 музыкаль номер карадык.

Аерып әйтәсе килгәннәрнең беренчесе – Зөһрә Сәхәбиева чыгышы. Аны быел «Легендар җырчы» номинациясендә бүләкләделәр. Җырчыны игълан иткәнче исә ул башкара торган «Җидегән чишмә» җырының язылу тарихын тыңладык. Тулаем алганда, премиянең исеменә һәм асылына туры килгән чыгыш булды ул.

Татар җыр сәнгатендә исемнәре күптән билгеле булган Винера Ганиева, Зәйнәб Фәрхетдинова, Салават Фәтхетдиновның чыгышлары да тантанага саллылык өстәде. Яшьрәк башкаручылардан Вадим Захаров, Илсөя Бәдретдинова, Зөлфирә Шәйдуллина, Ришат Төхвәтуллинның чыгышлары аеруча көчле алкышларга күмелде. «Күңелләргә үтеп кергән җыр», «Елның иң популяр җырчысы», «Халыкчан башкару», «Татар җыр сәнгатенә керткән өлеше өчен» номинацияләрендә җиңүләре шунда ук акланды дип әйтәсе килә.

Бер «Алтын йолдыз»ны икегә бүлүчеләр, ягъни гаилә дуэтларының күп булуы белән дә истә калыр бу тантана. Җиде җырлы гаилә җиде төрле номинациядә бүләкләнде. «Иң-иң»нәрне санасак, озакка китәр. Татар эстрадасының үзенә күрә бер феноменына әйләнгән бу күренеш озак яшәсен, җырчы гаиләләр туып торсын! Премияләрдә генә номинацияләр бүлү авыррак булыр инде…

***

Монысы бу чараның асыл-эчтәлегенә кагылмый. Әмма бер нәрсәнең үзгәрмәве, киресенчә, төрле яклап артуына игътибар итми мөмкин түгел. Җырларның берсенә берсе охшаш булуы турында күп сөйләшәбез, премиядә дә андый җырлар яңгырады. Ләкин тышкы яктан да индивидуальлек юк дәрәҗәсендә бит. Бу сезонда ялтыравыклы тукымалар галәмәт актуальдер актуален, ләкин сәхнәдә андый күлмәклеләр артып китсә, күзләр камаша башлый. Ничек кенә булмасын, бүген тамашачыга матур җыр гына түгел, матур, үзенчәлекле тамаша да кирәк. Һич югы бер ялтыравыклы күлмәкне икенчесенә алыштырып шаккатырырга була!

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ПРЕМИЯДӘ БАШКА НОМИНАЦИЯЛӘРДӘ ҖИҢҮЧЕЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

ОСТАЗЫБЫЗ

Табигать-ана аңа сәләтне өеп биргән, тыйнаклык, олы җанлылык кебек сыйфатларны да күпләп өләшкән. Сүзебез – бу көннәрдә 80 яшьлек юбилеен билгеләп узучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Азат Гани улы Сункишев турында.

Аның белән тәүге очрашуым Апас районында нәшер ителүче «Йолдыз» газетасы редакциясендә булды. Укуны тәмамлагач, туган ягыма кайттым. Үтә итагатьле баш мөхәрриребез Рифкать Әхмәтҗанов мине эшкә авыл хуҗалыгы бүлегенә билгеләде. Бүлек мөдире – Азат Сункишев. Ул һәркемне язу серләренә өйрәтә. Энциклопедик акылга ия, дөньяның төрле кыйтгаларында яшәүче татарлар тормышыннан да хәбәрдар. Бер минут та эшсез торганын хәтерләмим. Ул һәрчак эзләнүдә, хәрәкәттә. Командировкаларга велосипедта чыгып китә. Саллы материаллары апаслылар күңелендә зур кызыксыну, ихтирам уята.

Ул – Әлки районының Иске Салман авылыннан. Әнисенең бертуган энесе – күренекле татар язучысы Абдулла Алиш. Нәселдәнлек җепләренең чагылышы булып, Азат Гали улы да зур иҗат дөньясында кайный. Апасның үз кешесенә әверелеп, аның тарихын барлап, дөньяга чыгара. Аның хакында еш кына: «Апасның энциклопедиясен булдырган чын патриот», – дип юкка гына әйтмиләрдер. 1976 елда рус телендә нәшер ителгән «Голубые свитки Свияги» очерклар җыентыгы өчен, район газетасы журналистларыннан беренчеләрдән булып, Татарстан Журналистлар берлегенең Х. Ямашев исемендәге премиясе лауреаты була.

Унбер китап, күпсанлы брошюралар авторы да ул. Апас җирлегенең көнкүреш-яшәешен, халкының килеп чыгышын өйрәнү өчен никадәр архивларда казыну, тарихчылар – җирле халык белән әңгәмәләр кору – болар барысы да – Сункишевның яшәү рәвеше. 3 томлы энциклопедия туплау ничәмә еллар буе аңардагы иҗат газаплары, зур көч сарыф итүе һәм һәр нәрсәне үз хисабына бастыруы зур батырлык үрнәге түгелмени?!

Өч томлык «Минем хәтер китабым» дип атала. Аңардагы уй-кичерешләргә хәйран каласың. Максатчан, чын иҗат газаплары аша безне үткән гасырлар белән тоташтырды. Абыйсы Абдулла Алиш иҗатын да пропагандалау – аның намус эше. Университетны тәмамлаганда, диплом эше итеп «Абдулла Алишның журналистик эшчәнлеге» темасын алган булса, шагыйрьнең 100 еллык юбилее уңаеннан «Туган илем, барлык рухым синә, барысы синең өчен» китабы басыла. Ә Абдулла Алишның 110 еллыгы уңаеннан «Һәйкәлеңә чәчәкләр» китабы киң катлау укучылар хозурына тапшырыла. Азат Сункишевның янәшәсендә һәрчак якын бертуганнары, республиканың атказанган, танылган педагогы Илсөяр Сункишева, Гөлшат Сункишева булды. Бу – туганлыкның, бердәмлекнең ачык чагылышы.

Азат Гали улының бихисап бүләкләре арасында «Апастовская историко-краеведческая энциклопедия»сенең 3 нче томы, рус телендә нәшер ителеп, Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булган иде. 2004 елдан ул Апасның мактаулы (почетлы) гражданины, районыбызның 90 еллыгы уңаеннан медальгә лаек булды. Бу синең хезмәтеңне бәяләү, зурлау түгелме?!

Азат абыйның хәтер күгендә бергә эшләгән хезмәттәшләре Язилә Абдулкадыйрова, Хәмзә Бәдретдинов, Вахит Харрасов, Мөршит Галимҗанов, Фиргать Газизуллин һәм башкалар саклана. Гадел, кешелекле коллектив, гомумән, Апас халкы үзе үк риясыз, юмарт күңелле.

«Йолдыз» газетасында Азат абыйның дәвамчылары тарихның яңа битләрен ача. Баш мөхәррир Гүзәл Хилавиева зирәк акыллы: ул өлкәннәрне дә, хезмәттәшләрен дә бердәй зурлый. Азат Сункишевка исә урын һәрчак түрдән. Чөнки ул – күптән Апасның үз улына, газиз баласына әверелгән шәхес, апаслылар аңа зур хөрмәт белән «якташыбыз» дип дәшә.

Алсу БИКБАЕВА

Кышны көтәм

Кышны көтәм, балачагымда ук
Яратканга карлы буранны.
Күпләр хафалана,
мин шатланам,
Басып китсә көртләр урамны.

Кышны көтәм,
салкын төннәрдә дә
Сулаулары авыр булса да.
Тик кышларын яңа яуган карда
Матур булып безнең эз кала.

Кышны көтәм...
Бары кышкы салкын
Яраттыра белә чамасыз.
Кышны яратыгыз минем кебек,
Бәлкем сез дә илһам алырсыз.

Римир СӘЛИМГӘРӘЕВ

Илдар Мөхәммәтҗанов

ТӘРТИПЛЕ КЕШЕ

Тәртипле кеше дигәндә мин гомерем буе авылыбыздагы данлы һөнәр иясе – тимерче Яхъя бабайны исемдә тотам. Бәләкәй чагымнан ук аның хакында инәкәебезнең әткәйгә тәртип турындагы бер халәт-рәвешен сөйләгәне-әйткәне күңелдән чыкмый – инде күпме еллар үткән. Әнә күршесе Рәхимә көянтәсе белән шифалы коесына суга кергән дә, капкасын япмыйча калдыргач, аның артыннан кереп, суын алып чыгып, кире коесына салган! Менә сиңа мә – тәртип, яңадан инде капка һәрвакытта да ябыла торган булган! Әнә шуңа йортында да, тимерчелегендә дә үтәдән-үтә тәртип хөкем сөргәнгә, Яхъя картның ихата тирәләреннән үк үзенең төгәллек-матурлык оештырганлыгы белән һәркемне янына чакырып тора иде. Бу төгәллек бүген дә аныңча дәвам итә: Яхъя бабайның юклыгына озак вакытлар үтсә дә, аның бу үрнәк сыйфатларын һаман саклап, онытмыйча сөйлиләр, заманында иң кирәкле тимерче һөнәре иясенең осталыгы, үтә игелекле, ярдәмчел, гадел булуына аерым тукталып әйтәләр безнең Югары Стәрле авылында, сүз сөрешендә: «Яхъя бабай кебек бул!» – дип тә куялар. Әнә күршеләре Октябрь революциясе кебек орденнар кавалеры, танылган игенче-механизатор Мирза аганың улы Рәшит Нургалиевның исеме еракларга билгеле. Татарстанның атказанган нефтьчесе, пенсиягә чыккач, ювелирларча ясаган буровой установкалары, станок-качалкалар, күтәргечләр, чылбырлы үткәргеч-приводларның модель макетлары эшче һөнәрләренең Казанда үткән дөнья чемпионаты күргәзмәсендә югары бәя ала. Монда катнашучы Көньяк Корея, Румыния вәкилләре дә аңардан әлеге минимаркетларны ясауны сорыйлар. «Яхъя бабайдан шундый төгәллек-тәртипкә өйрәнеп үстек инде», – дип тикмәгә әйтмидер Азнакай Кулибины үзенең осталыгы турында.

Әлеге җәһәттән Нәкый Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» өченче томлыгының «Эшне формаль үтәү һәм үз эшеңә җаваплылык» бүлегендәге берничә мәкальне дә китерергә уйладым.

Кем башлаган, шул бетерергә тиеш.
Көн үтсен дә төн үтсен,
калганына кар яусын.
Үз эшеңә үзең җавап бир...

Әйе, тәртипле эштән, тәртипле кеше кулыннан гына тәртипле, җиткелекле – тулы канлы тормыш-яшәеш көтеп була. Тәртипле кешедән генә тәртипле эш туа, үз һөнәренең остасы барлыкка килә. Шуңа тикмәгә генә «Һөнәр остасы – ил тоткасы» димиләр. Куанып әйтик: хәзер яшьләрдән бик күп шундый үтә тәртипле осталарга тукталырга мөмкин. Менә минем Азнакай шәһәрендә яшәүче Илтөзәр Хөсәенов дигән танышым: аның дөньялыкта белмәгән берәр шөгыль-һөнәре калды микән. Әнисе Әзһәрия апа (урыны оҗмахта булсын) аңа шултиклем белеп кушкан исемен: Илтөзәр! Ул чын мәгънәсендә ил төзүче: пластик торбаларны җылытып ябыштырып, су кертү, җылыту линияләре сузу, электр белән эретеп, җитмеш төрле конструкция ясау, борыс, кирпеч һәм башка материаллардан йортлар төзү дисеңме яки нинди генә машиналарны көйләп-ясап йөртми ул. Кайсы гына төрдәге кошларны үз инкубаторында чыгарып, күзләрне кызыктырырлык итеп асрап та күрсәтә. Оста аучы-мәргән. Яшелчәчелек, бакчачылык остасы янә. Үзенең яшел аптекасында шифалы үләннәрне дә аерым тәртиптә тота, чәй ишене дә кибеттәгене түгел, үзенекен үз итәр. Һәм аңа карап уйлап куям: әнә шундый тәртипле эш-һөнәр осталары тотып тора бит инде безнең тормыш-яшәешебезне – чын мәгънәсендә ил төзүче Илтөзәрләр, тимерче Яхъя бабайлар.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы

БЕР ЯЛГАН СҮЗ

< Башы 21 ноябрь санындагы
«Һич онытасым юк» сәхифәсендә

Әни язмышы

Ләкин тынычлык озакка бармый. Күп тә үтми, чират әнисе – Бибигайшә Шәрәфетдин кызына җитә. Аны 1941 елның 10 июль көнендә колхозчылар болында печән чапкан вакытта, эшләгән җирендә кулга алалар. 17 сентябрьдә, Совет хөкүмәтенә каршы сөйләүдә гаепләп, 10 елга лагерьга озаталар. Инде ару тормыш алып баручы ирен, аның артыннан ук 5 яшьлек баласын югалткан, бернинди мал-мөлкәтсез 3 баласы белән кара мунчада яшәп ятучы 53 яшьлек хатын кемнеңдер тамагына кылчык булып тыгылган диярсең.

Карлы авылының «Кызыл Йолдыз» колхозчысы Сания Гыйматдин кызы истәлекләреннән: «...Бибигайшә апага судны Буа шәһәрендә үткәрделәр. Без – колхозчыларга да анда барырга куштылар. Зал тулы халык иде. Суд якынча 5 минут тирәсе булды. Прокурор гаепләү белдерде: имеш, Бибигайшә апа Кадир абыйлар мунчасында юынганда, бер хатынга, менә Гитлер килсә, Совет хөкүмәте бетәчәк, җирләребез үзебезгә кайтачак, дигән. Ул мунча юлдан ерак, анда кычкырып сөйләшсәң дә, юлдан баручы кеше берни ишетмәячәк. Аны инде милиция хезмәткәрләре килеп тикшереп караган иде. Прокурор ул тикшерүне карап та тормады, искә дә алмады. Гаепләү сүзе бетүгә, судья хөкем карарын җиткерде. Бибигайшә апа шунда янәшәдә генә басып тора иде. Ул судьяга карап: «Монда сез Һитлер, Һитлер дип нидер сөйләдегез, нәрсә соң ул Һитлер?» – дип мөрәҗәгать итте. Судья, папкасына документлар тутырган җиреннән тукталып, аңа бераз текәлеп карап торды да, алданрак уйларга кирәк иде, дип тиз генә бүлмәдән чыгып китте. Бибигайшә апаны төрткәләп милиционерлар алып киткәндә, бар халык елап калды. Ул, авылдашларымны башка күрә алмам дип, каерылып, безгә карап калырга талпынды. Габитовлар өстеннән донос язучы – үзебезнең авыл хатыны, аны барысы да белеп торды. Ул әле тагын берничә кешенең башына җитте». Бибисараның әнисе Зөя утравындагы 5 нче колониядә 4 айдан вафат була. Әнисе вафаты турындагы хәбәр авылга 1942 елның февраль аенда килеп ирешә.

Туган җирдә

Сугыш башлангач, эшчеләр фабрикада яшәп, эшләргә тиеш була. Кемнең яшь баласы бар, аны балалар йортына биреп, эштә кала. Баласыннан аерылмаса, шәһәрдән китәргә тиеш була. Бибисара ике баласы белән туган авылына юл сайлый. Әйберләрен төенчекләргә туплап, Казан вокзалына киләләр. 3 тәүлек вокзалда көтеп җәфаланганнан соң, Казанга кайтып җитәләр. Аннан Карлы авылына, ире Низамның туган йортына. Үзе белән алып кайткан әйберләрен сатып, тиз арада сыер сатып ала – балаларга сөт, азык кирәк. Алар артыннан авылга төрле яклардан качаклар килә башлый. Авылның мәчет бинасында балалар өчен бакча оештырыла. Килгән халык барысы да рус телле булгач, русча белүче кеше кирәк була. Бу чакта «халык дошманы»ның кирәге чыга. Чөнки ул инде Мәскәүдә яшәгәндә чит телне яхшы үзләштерә. Карлы авылында эшкә түләү, ашарга ризык булмагач, Бибисара Буада тегү артеленә урнаша, анда хәрби киемнәр тегәләр. 1942 елның язында туган йорты җирендә бәрәңге утырта. Шул арада кара мунчада яшәп яткан ике ир туганы фронтка китәләр. Сугыш тәмамлангач, тегү артелендә эш бетә. Бибисара колхозның тавык фермасына эшкә урнаша. Ире Низам фронттан кайткач, ике ир бала – 1947 елда Фарукны һәм 1949 елда Вазыйхны таба.

Әлбәттә, Бибисараның гаиләсе өстенә бер-бер артлы килеп торган кайгы-хәсрәтләр тормышны бизәми, сәламәтлеккә зур зыян китерә. Аларны йөрәк аша үткәрү аек акыл, сабырлык сорый. Нинди генә кайгы килсә дә, ул бала чагыннан күңеленә сеңдерелгән ислам диненә сыенырга тырыша. Авылда абыстайда укыганда өйрәнгән намазын калдырмый. Ярдәм өмет итеп, Коръәнгә мөрәҗәгать итә. Андагы аятьләрне, сүрәләрне укып, тынычлык таба. Гарәп телен беркайчан исеннән чыгармый. Аның өендә гарәп хәрефләре белән язылган берничә дистә китап совет активистларыннан да яшеренеп сакланып кала. Хәтта Мәскәүдән дә аларны күтәреп кайта. Шуңа Коръәнне, гарәп телендә язылган китапларны укып гомер итә. Ире Низам аның үтә зиһенлелегенә сокланып, күп тапкырлар, синең зиһенең белән галим булырга тиеш идең, дип әйтә.

Соңгы сүз. Бабасы Галиулла, ире Һидиятулла, әнисе Бибигайшә Шәрәфетдин кызы, әтисенең туганы Сөнгатулла – барысы да 1990 нчы елларда акландылар. Әмма бу игелек 60 ел элегрәк булырга тиеш иде. Миллионнарча гаиләләрне юк итәргә бер ялган сүз җиткән заман кире кайтмасын иде...

Расих ҖӘЛӘЛ. Карлы – Казан

«Гомерем – утлы кисәү»

Ул чагында да коеп яңгыр яуган иде. Күк йөзен каплап алган кара болытлар бер дә таралмас сымак иде. Ул чагында да көз үзенең соңгы көннәрен саный иде. Тик шәһәр урамнарының берсендә урнашкан тугыз катлы йортка барып җиткәнче, һич көтмәгәндә кояш та ялтырап чыкты, көн дә яктырып китте. Үземә кирәкле фатирны эзләп табып, төймәгә басам. Ишек шундук ачылып китә. Каршымда басып торган чал чәчле ханым, «кер, әйдә», дигәндәй, сүзсез генә миңа юл бирә. «Килгәнсең икән, сөйләшик, – ди ул теләр-теләмәс кенә. – Хәзер инде сөйләдең ни дә, сөйләмәдең ни. Кайтарып булмый...»

– Менә шулай илле яшемдә япа-ялгыз калырмын дип кем уйлаган? – дип башлый ул авыр сөйләшүне. Һәм кинәт кенә: «Кешене нахакка рәнҗеткәнең булдымы?» – дип сорап, мине аптыраштa калдыра. «Беркем дә андый хәлнең булганы юк дип әйтә алмый, – дим, – үзең сизмәстән дә эшләргә мөмкин бит».

– Юк, минем алай булмады. Белдем аның гаепле түгеллеген, шуны белгән килеш тә рәнҗеттем, – ди ул күңелендә давыл булып купкан үкенү хисләрен тышка чыгарып. – Ул миңа шул чагында: «Гомерең утлы кисәү булсын», – диде. Менә шул утлы кисәүдә инде мин – ни исән, ни тере... Иремнән бик көнләшә идем, – дип дәвам итә хатын.

Уйламыйча әйтелгән сүзнең зур тавыш-гауга китереп чыгарасын, әйтеп бетергесез хәсрәт-борчулар алып киләсен күз алдына да китереп карамаган ул. Аны өенендә дә, төшендә дә эзәрлекләгән ул каһәр көн тора-бара мәхшәргә әйләнә.

Бервакыт алар – ике тату-дус гаилә аның туган көнен табигать кочагында уздырырга ниятләп, җыйнаулашып урманга баралар. Балалар шундук шау-гөр килешеп, кайсы кая таралышып бетә. Ә алар дүртәүләп табын әзерләргә керешә. Бераздан аның ире, су алып киләм дип, елгага төшеп китә. Күпме вакыт узгандыр, дустының хатыны Алсу да юкка чыга. «Минем күңелгә шундук шик керде, – дигән иде ул шул чагында. – Икәү югалды бит болар».

Ул анда чаба, монда чаба. Елга буена да төшә. Таба алмый. Кире әйләнеп кайтса, алар көлешә-көлешә шашлык ашап утыра. Ул, аңгыраер хәлгә җитеп, Алсу каршына килеп баса да: «Җирбит, өстерәлчек!» – дип дөньяда калмаган сүзләр кычкырырга тотына. Көтелмәгән бу хәлдән барысы да өнсез кала. «Шул чагында Алсу катып калгандай булды. Ире исә, берни әйтми, җыенды да өйләренә кайтып китте. Ирем мине бик озак тынычландыра алмады. Бер мизгелдә бөтенесен дә юкка чыгаруымны, дус хатынымның гына түгел, үземнең дә тормышымны чәлпәрәмә китерүемне мин шунда аңладым», – дигән иде хатын шул чагында. Алсуны ире шул кичне бик каты кыйнаган дип сөйләгәннәр. Ул шуннан гарип калган, эшеннән китәргә мәҗбүр булган. Ә ире шул көннән соң, хатын белән сөйләшмәс булган. «Белеп тор, син нахакка кеше рәнҗеттең, әҗере үзеңә төшми калмас», – дип, бер генә җөмлә әйткән. Аннары... өйдән чыгып киткән. «Син бу көнне көнче сулышың белән тартып китердең. Син үзең шуны теләдең», – дигән ул киткәндә.

Хатынның күрәчәкләре моның белән генә бетсә икән... Аның уналты яшен тутырып килгән улы әтисен бик сагынган, юксынган. Әнисе белән аралашудан туктаган. Хатынның улы турында: «Балтасы суга төшкән кешедәй бер-ике ай йөрде дә үз-үзенә кул салды», – дип елаганы әле дә колакта яңгырап тора. Уйламыйча әйткән нахак сүздән дә яман нәрсә юк. Чөнки аның нәтиҗәсе, күргәнегезчә, куркыныч була, берсе дә эзсез югалмый, диясе килә. Ул сабыр гына үз сәгатен көтә. Күңелендә тынычлык булмаган, үз-үзенә урын тапмаган кешенең беркайчан да бәхете булмаячагы турында сөйләп тору кирәк микән? Биредә дә нәкъ шундый очрак. Әгәр дә сине үткәндәге уйлар бертуктаусыз эзәрлекли икән, син гомер буе шул хәлләргә килеп кабачаксың. Шул рәвешле тормышыңдагы яңа үзгәрешләргә киртә куячаксың. Әйе, тормышның үз тәҗрибәсе, үзенең гыйбрәтле сабаклары бар аның.

Мәдинә АВЗАЛОВА

Кызыма

Офыкларны болыт сарган чакта,
Сабырлыгым җуеп тезләнәм.
Кояш кебек балкып кайтып керсәң,
Борчуларны онытып, үзгәрәм.

Йөрәгеңнең кайнарлыгы күчкән
Кулларыңа хәтле сихәтле.
Күңелемне минем иркәләгән
Җылы хисең – нәфис ефәктер.

Аң-зиһенең тере чаткы кебек
Балкып, дөньяларны яктырта.
Пыскып беткән хәлдә, тернәкләнәм,
Янда шәфкатьле зат бар чакта.

Гаҗәеп бер күңел сизгерлеге,
Төпле акыл каян бирелгән?
Киңәшләрең гел коткарып килә
Җанга үрмәләгән төердән.

Өметемә канат үстерәсең,
Төпле фикер белән юатып.
Я кем тагын утлар йотар икән,
Әнкәсе өчен ихлас җан атып.

Миңа кылган фида игелегең
Меңе белән кайтсын үзеңә.
Синең тылсым көчең бик куәтле,
Хәтта корган гөлләр терелә.

Миһербанлы күңел дәрманыңнан
Файда күргән, әйдә, күп булсын.
Тулы бәхетләргә тоташтырсын
Бик мәгънәле, гамьле тормышың.

Фәридә ШАКИРОВА

Үз илемдә – үз телем

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстандагы төрле милләтләрнең яшәеше, гореф-гадәтләре белән таныштыра, «Бер гаилә мисалында туган телне ничек сакларга?» дигән сорауга җавап эзли.

ТӨРЕКМӘН

Казан

САБЫРЛЫК ҮРНӘГЕ

15 ел буе каенатасына бер сүз дәшмәгән килен, өлкәннәргә баш иеп исәнләшү, гаилә башлыгы кайтмыйча, табынга утырмау... Казанда яшәүче төрекмән гаиләсе – Гунча белән Ялкап Нурҗановлар безне сабырлыгы белән гаҗәпләндерде. Әлеге гаиләнең Казанга күченеп килү тарихы да башкаларга охшамаган. «Бәхетсезлек булмаса, бәхет булмас иде», – ди алар. Кардәшләребезгә Татарстанны үз итү өчен сигез ел түгел, бер көн җиткән.

Әти кайткач...

Казандагы дүрт бүлмәле фатирларында яшәүче Нурҗановлар безне идәнгә табын җәеп каршы алды. Махсус түгел, кичке аш вакыты иде. Үзбәк, кыргызлар гына түгел, төрекмәннәр дә идәнгә утырып ашый. Гаилә башлыгы Ялкап эштән, дүрт баланың икесе түгәрәкләрдән кайтып җитмәгән иде әле. Олы улы Рөстәмгә – 14, Атагелдигә – 12, Булатка – 10, Ясминәгә – 2 яшь. Әбиләре Фидания апа да балалары белән бергә яши.

– Без, ирем эштән кайтмыйча, табынга утырмыйбыз. Идәнгә җаймә җәеп, ризык әзерләп, әтиебезне бергәләп көтәбез. Берәү дә түземсезләнеп кашыкка беренче булып үрелми. Әгәр инде кичке сәгать 9дан соңга калса, кичке ашны аннан башка ашыйбыз. Ялкап таләпчән булганга түгел бу. Бездә кагыйдәләр шундый, – дип, Гунча ашау-эчү тәртибе белән таныштырды.

Өстәлгә салатлар кую гадәте юк икән. Гадәттә, үзләре үстергән анар, карбыз, виноград, хөрмә кебек җимешләрне тезәләр. Милли ризыклары – пылау һәм дограма. Хуҗабикә нәкъ менә дограма әзерләгән иде. «Пылауны ашаганыгыз бардыр, ә менә монысын юктыр әле. Сезне дә авыз иттерәсем килде», – диде хуҗабикә. Шулай ук фатирга бишме исе таралган иде. Монысы – майда пешкән камыр ризыгы.

Кичке сәгать 8дә түгәрәктән уллары кайтып җитте. Һәрберебез белән кул биреп күрешеп чыктылар. Аннан инде әтиләре дә көттермәде. Ишектә кыңгырау шалтырады. Балалар барысы да шунда таба йөгерде. Кочаклашып, бер-берсенең хәлләрен сораштылар. Иң ахырдан Гунча иренең бит очыннан үбеп, табынга дәште. Ашарга ярый! Иң беренче булып ашны Ялкапка сузды ул. Ирне беренче булып сыйлыйсы.

Нурлы Казан!

Ашап-эчкәч, гаиләнең Татарстанга килү тарихы турында сораштык. Баксаң, әниләре Фидания апа Казан кызы икән. Кунакка дип килгән төрекмән егете Овезгельди белән танышып, шул якларга кияүгә чыккан. Аның белән ике кыз тәрбияләгән. Чит җирдә утыз ел гомер кичергән. Тик шулай да туган якка эзен суытмаган, әти-әнисе янына кайтып, хәлләрен белешеп торган. Фидания апаның ире 19 ел элек вафат булган.

Җан тартмаса да, кан тарта, диләрме әле? Дөресрәге, Гунча белән Ялкап Казанга үзләре теләп түгел, мәҗбүри килә. Фидания апа 6 яшьлек оныгы Рөстәмне ияртеп, Казанга Сабантуйга кайтып киткән. Гунчаны ире кисәтеп куйган: «Әгәр улыбыз белән берәр хәл килеп чыкса, үзең җавап бирәсең». Үч иткәндәй, шулай килеп чыга да. Бәйрәм көнне батутта сикергәндә, Рөстәм кулын сындыра. Бу хакта әти-әнисенә хәбәр иткәч, алар бик борчыла. Бер көн эчендә акчасы, билеты да табыла, виза ясатырга да җай чыга. Шулай итеп, Нурҗановлар Казанга оча.

– Операция уңышлы узды. Иремә Казан бик ошады. «Әйдә, документларны әзерлик тә монда күченеп килик», – дип, үзе тәкъдим итте. Шулай итеп, биредә сигез ел яшибез инде. Төрекмәнстанда өебез дә, машинабыз да бар иде. Татарстанга килгәч, тормышны өр-яңадан башларга туры килде. Эш тә, дуслар да таптык. Мин – хисапчы, ирем наладчик булып эшли. Бер оешмада хезмәт куябыз. Безгә барысы да хөрмәт белән карый. Балалар 40 нчы гимназиядә белем ала, – ди Гунча. – Әни – тормыш токтасы. Аннан башка беркая да китеп булмый. Бөтен ирешкән уңышыбыз өчен аңа рәхмәтлебез. Без эштә булганда, балаларны мәктәпкә озата, каршы ала.

Сүз уңаеннан, Гунча белән Ялкап икесе бер сыйныфта укыган. 16 яшьтә икесендә дә тәүге сөю хисе кабынган һәм биш елдан соң гаилә корган алар. Хәзер икесенә дә – 38 яшь.

Тел яшерү

Нурҗановларда безне гаҗәпләндергән нәрсәләр дә аз булмады. Төрекмәннәрдә килен белән каената арасында сөйләшмәү гадәте бар икән. Үпкәләшүдән, бер-берсен яратмаудан түгел бу. Әнә Гунча каенатасы Аганазар белән 15 ел аралашмый инде. Ничек түзә диген, әмма аңа карап хөрмәте бер дә кимеми.

– Каенатаны күргәндә, битне яулык чите белән каплап, башны иеп, сәлам бирәбез. Сөйләшмичә тору өчен сабырлык кирәк, әлбәттә. Бу – хөрмәт билгесе. Алтыннан берәр эшләнмә яки кыйммәтле яулык, тукыма, савыт-саба биргән очракта гына сөйләшергә ярый. Әлегә каенатам миңа бүләк бирмәде. Хәзерге вакытта ул Төрекмәнстанда яши. Бик әйбәт кеше. Иремнең ир туганнары янында да әдәп саклыйм. Ирләр утырган бүлмәгә хатын-кызларга керергә ярамый. Кирәкле әйберләрне балалар аша гына бирәбез, – дип сөйләде Гунча.

Хатын-кызга чәчне күрсәтергә ярамый дигән таләп юк. Төрекмән хатын-кызларының күбесе яулыкны чәчне күрсәтеп бәйли.

Кагыйдәләр

Гунча балаларын кечкенәдән эшкә өйрәтеп үстерә. Суыткыч ишегенә балаларның өйдә кизү тору графигы эленгән. Уллары көн саен чиратлашып өй җыештыра, тузан сөртә, кухняда булыша. Манты, бәлеш, өчпочмакмы – уллары әниләренә барысын да ясаша. Түгәрәкләрдән кайтып, өй эшләрендә булышкач, балалар дәрес әзерләргә утыра. Кечкенә Ясминәнең генә мәшәкате юк. Мультфильм карый, рәсем ясый, китаплар актара. Әнисе аңа табынга утыру кагыйдәләрен аңлатырга тырыша.

– Өегездә нинди таләпләр бар? – дип тә сорадык хуҗабикәдән.

– Чисталык булырга тиеш. Моны һәркем белә. Каядыр барасы булса, өйдә калган кеше, берәр нәрсәңне онытмадыңмы, дип башкаларның исенә төшерә. Шуңа күрә бер нәрсә дә онытылмый, – ди ул.

Өйдә төрекмәнчә генә сөйләшәләр. Тыңлаган җырлары да – үзләренеке. Балалар туган телләрен, гореф-гадәтләрен белеп үсә.

– Олы улларыбыз төрекмәнчә яхшы сөйләшә. Кечкенәрәкләр белмәгәнне алар аңлата. Әгәр инде шуннан соң да аңламасалар, без ярдәм итәбез. Җәйге каникулда балалар Төрекмәнстанга әби-бабайлары янына кунакка кайта. Казандагы якшәмбе мәктәбенә йөриләр. Телне менә шулай өйрәнәләр, – ди Ялкап.

ВИДЕО

Сәхифәне Сәрия МИФТАХОВА әзерләде
Фото – Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ

Милли ризык

Бишме

Ярты литр сөт, ярты литр су, тоз, шикәр комы, бераз чүпрә кушып, камыр басарга. Шуны җәеп, ромб формасында кисеп, майда кыздырырга. Өстенә шикәр пудрасы сибеп, табынга бирергә.

Дограма

Моның өчен 1 кг он, ярты кг ит (сөякле булса яхшы), 300 грамм суган һәм тәменчә тоз кирәк.

Суга тоз, он кушып камыр басарга да 15–20 минут ял иттереп алырга. Камырны җәеп, өстенә май, 10 минутка төреп куярга кирәк. Катлы камыр килеп чыга. 1 сантиметр калынлыкта җәеп, духовкага тыгасы. Пешкәч, аны бераз пакетка салып торасы.

Ит, бер баш туралмаган суган, борыч салып, шулпа әзерлисе. Итне дә, «ипи»не дә вакларга кирәк. Шуңа суган турыйсы. Бөтенесен бергә болгатып, өстенә шулпа өстисе. Ризык табынга шулай бирелә.

Гореф-гадәтләр

Туй йоласы

Төрекмәннәрдә туйлар гөрләп үтә. Кунаклар 300дән дә ким булмый. Егет калымны мулдан әзерли. Кәләшкә алтын йөзек, алка, муенса, кыйммәтле яулыклар бүләк итсә, кызның әти-әнисенә 100 мең сум акча бирә. Гадәттә, бу акчага телевизор, кер юу машинасы, көндәлек кирәк-ярак сатып алалар.

Кәләшне «яңа килен» дип йөртәләр. Битенә милли көртә каплаган кәләш каената һәм каенасы белән башын иеп, өч мәртәбә исәнләшә. Кызлар кияүгә чыкканда, милли оекбаш, ягъни төрекмәнчә машат джорап кия. Аннан аны үз кызларына дип саклыйлар.

Туй беткәч, кунаклар таралышса да, кәләш белән кияүнең дуслары, сыйныфташлары китәргә ашыкмый. Кияүнең биленә яулык бәйлиләр. Сөйгәне шул төеннәрне чишәргә тиеш. Аннан егет, сезгә дә насыйп булсын дип, әлеге кулъяулык белән иптәшләренә сугып чыга. Егетләр урамга чыгып, тәрәзәгә шакый. Шуннан соң кәләш тәм-том тутырылган савытны тәрәзә аша иренә суза. Ә ул башкаларга тарата.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 13596 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 364

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+